# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

1/ 2025

**Тәкә мөгезе рәвешендәге бизәк – уңдырышлылык һәм нәсел дәвамы символы булып санала. Мөгез өстендәге бадәм формасындагы орлык шулай ук әлеге символны ассызыклый. Ул болгарларның игенчелек культурасы белән бәйле традициясен дә чагылдыра**







# «Башкалабызның бриллианты»




**Быелның 20 гыйнварында, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының еллык коллегиясе кысаларында, Камал театрының яңа бинасын рәсми ачу тантанасы узды.**

**Тантанага Мәскәү кунакларыннан Россия мәдәният министры Ольга Любимова, Россия Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллин, Россия Театр әһелләре берлеге җитәкчесе Владимир Машков һәм Россиянең 81 субъектыннан вәкилләр килгән иде. Әлбәттә, театр бинасы Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында ачылды.**

Театрда 4 зал бар. Ул бер мең ярым тамашачыны сыйдыра ала. Пыялалы ишекләрдән килеп кергә – киң фойе. 11 метр биеклектәге стеналарда милли бизәкләр. Алар төрле үрнәктә. Паннолар рәссам Наилә Кумысникова белән бергәлектә башкарылган.

Заллар да төрле: кәнчыгыш зал уртасында түгәрәк сәхнә. Диварларындагы түгәрәк панельләр – татар хатын-кызларының бизәнү әйберләре ясалган талир тәңкәләрне хәтерләтә. Зур тәрәзәдән Кабан күле, шәһәр күренеп тора. Шулай ук кинолар да төшерергә яраклы кап-кара универсаль зал бар. Тагын кече һәм зур зал.

Ультразаманча төзелгән бинада спектакльләр генә күрсәтелмәячәк. Анда төрле лабораторияләр, театраль остаханәләр эшләячәк, гомумән, төрле чаралар оештырылачак.

Тантаналы ачылышта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов: «Хәерле сәгатьтә! Эшләгән эшләребезне Ходай кабул итсен! Киләчәктә дә шундый матур биналар һәм яхшы эшләребез булсын! Шушы матур бинада барыгызны да күрүемә шатмын. Бу – Татарстанның гына түгел, зур илебезнең казанышы. Бу бинаны төзү өчен уздырылган халыкара бәйгене оештыручыларга рәхмәт! Театрның тышкы күренеше дә дөрес карар булды дип саныйм. Икенчедән, урын сайлау өчен шәһәр администрациясенә – Илсур Метшин командасына рәхмәт! Без элеккеге бинадан ерак булмаган дөрес урын сайладык. Бу – башкалабызның иң матур урыннарының берсе. Безнең проект институты һәм төзүчеләребез булмаса, шулкадәр кыска вакыт эчендә төзи дә алмас идек. Иң мөһиме – безнең иҗади потенциал бар. Бу театр гына да түгел, монда мөмкинлекләр зуррак. Бу – башкалабызның бриллианты, республика өчен генә түгел, илебез өчен дә зур үзәк була ала – без шуңа омтылырга тиеш!» – дип белдерде.



Фоторәсемнәр Татарстан Рәисе рәсми сайтыннан һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы сайтыннан

# Эчтәлек


ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ



4 «Язмышлар үрелеше»

6 «Царицыно» музей-тыюлыгында «Чигү остаханәсе: тамбурлы җөй» проекты булып узды

8 «Уникаль Россия» күргәзмәсендә Татарстан Республикасы экспозициясе эшләде

10 Халык сәнгате һөнәрләре проблемаларына багышланган семинар

ХАЛКЫМНЫҢ ОСТА КУЛЛАРЫ



12 Г. Вәлиева-Сөләйманова **Тирмә – киез йорт**

ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...



22 Х. Баһаветдинова **Мәчти авылы кымызчылары**

ӘДӘБИ МИРАС

28 Л. Мөхәммәтҗанова **Мәзәкләрдә – күңел көрлеге**



**Түгәрәк уен**
№1 (55 ) / 2025


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 12.03.2025
Чыгу көне: 26.03.2025
Заказ: №68. Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
тел.: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

Отпечатано в ИП Селиванова А.Г.
420015, Казань, Галактионова, 14
тел.: +7(843)2382449
E-mail: Orange_k@list.ru



Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.


**Тышлыкта:** Тирмәне уратып алган бизәкле кашага орнаменты.
Дизайнеры Энҗе Кыямова


© «Түгәрәк уен», 2025

МИФОЛОГИК МИРАС



34 Г. Гыйльманов
**Арбаулар**

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ БӘЙРӘМНӘРЕ



40 Э. Сәлахова
**Тәтеш төбәгендә халык бәйрәмнәре**

БЕЗГӘ ЯЗАЛАР



48 Л. Хәкимова
**Арчаның үз бизәкләре бар**

БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ




50 **Мактымсылу**

БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...



53 **Туган тел көне иртәсендә...**

54 Р. Степанова
**Тукай безнең көннәрдә...**

56 **Мәче белән шагыйрь** *(җыр)*

ӨЙ КҮРКЕ – АШ



57 **Ризаэддин Фәхреддиннең «Әхлак гыйлеме» китабыннан...**

60 **Бәрәңге шаңгәсе**

ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

62 **Бергәләп бизибез!**

# «Язмышлар үрелеше»



**2024 елның 21 декабре-2025 елның 26 гыйнварында Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» галереясында декоратив-гамәли сәнгать рәссамы, татарларның күн мозаикасы остасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Светлана Гарбузова күргәзмәсе эшләде.**

Светлана Юрьевна – гаилә традициясен дәвам итүче нәселдән килгән рәссам. Аның профессиясе – иҗаты гына түгел, язмышы да, һәм бу язмыш аны әнисе – республикабызда күн эшләнмәләр белән шөгыльләнүче беренче профессиональ рәссам Софья Даниловна Кузьминыхтан башланган традиция белән бәйләнгән.

1960-70нче елларда Казанда гамәли сәнгать осталарының шактый көчле коллективы туплана. Алар арасында Софья Даниловна Кузьминых алдынгы урыннарның берсен били. Күн сәнгате остасы буларак, ул аны эшкәртүнең төрле ысулларын – мозаиканы, чокырлап бизәкләр төшерүне, көйдереп рәсемнәр ясауны, аппликацияне үзләштерә, үзенең кызы Светланага да күпертеп чигү (тамбур), ефәккә рәсем төшерү осталыгын өйрәтә һәм анда татар мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияли. Аларның уртак язмышы ике буын рәссамнарның мирасны төрлечә кабул итүче иҗади хезмәттәшлегенә әйләнә.

С. Гарбузова иҗатының башлангыч этабы монументаль-декоратив сәнгать өлкәсендәге эш белән бәйле була. 90нчы еллар башында ул С.Д. Кузьминых белән берлектә йомшак сукнога кызыл-зәңгәр эре орнамент үрнәкләре төшерелгән «Казан бизәкләре» дип аталган, образлылыгы ягыннан ачык, үзенчәлекле дивар келәме иҗат итә. Шулай ук бергәләп, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының «Зәңгәр шәл» спектакле өчен бик матур яулык бизәкләп эшлиләр.







Светлана Гарбузова татар күн мозаикасы сәнгате үсешендә тагын да зуррак уңышларга иреште. Башка халыклар иҗатында очрамый торган бу уникаль техника үзенең югары сәнгать үзенчәлекләре белән дөньякүләм танылу алды. Рәссам, жанр һәм сәнгати техника осталыгын киңәйтеп, күн мозаикасы әсәрләренә яңа сулыш бирде. С. Кузьминых кебек үк, бу сәнгатьне үзләштерүне ул традицион эшләнмәләр – татар орнаментларына хас бизәкләп эшләнгән читекләр, диван мендәрләре иҗат итүдән башлады.

Мозаика сәнгатенә С. Гарбузова Арчадагы халык осталарыннан өйрәнде, бизәкләр кисүдән башлап, аларның чигелешенә кадәр барлык чигү техникасы процессын үзләштерде. Оста үз иҗатында күн мозаикасын киемнәрне декоратив бизәкләүдә файдалану, жакетлар, читекләр һәм аларны тулыландыручы сумкалар, билбаулар һәм башка аксессуарларны эченә алучы киемнәр ансамбле тудыру кебек яңа ысуллар куллана. Моннан тыш, үз әсәрләрендә ул алтын җепдән оста файдалана, бу исә эшләнмәләрнең декоратив образын баета, алтын җөй белән чигелгән кызыл читекләр кебек, аларга мәһабәтлек төсмере бирә.



**Күргәзмәдә 35тән артык эшләнмә (панно, читекләр, келәм, зәңгәр шәл һәм башкалар) – Светана Гарбузованың үз әсәрләре дә, Софья Кузьминых белән бергә иҗат ителгәннәре дә урын алды. Шулай ук «Казан бизәкләре» келәменә өстәмә буларак, Петр Сперанскийның орнамент эскизлары да тәкъдим ителде.**

# «Царицыно» музей-тыюлыгында «Чигү остаханәсе: тамбурлы җөй» проекты булып узды




**2024 елның 11 декабрендә Мәскәүнең «Царицыно» Дәүләт музей-тыюлыгында татар сәнгать һөнәрләре һәм аларның шәһәр мохитендәге үсеше күргәзмәсе ачылды.**

Экспозициягә 400дән артык экспонат куелды, алар арасында XII гасырның болгар алтыны, Алтын Урда чорының көмеше, XIX гасыр азагының күн мозаикасы, чигүле һәм ювелир эшләнмәләре, шәһәр көнкүреше предметлары һәм татар мәдәнияты феномены булып киткән атаклы шамаил дә бар иде. «Шәһәр һәм һөнәрләр: Казанда очрашу. Идел буе татарларының традицион сәнгате» күргәзмәсе «Царицыно»ның Россия мөселман регионнары мәдәниятенә һәм традицион сәнгатенә багышланган проектлар сериясен дәвам итте. Яңа проект – татар халык сәнгатенең Урта гасырлардан алып, безнең көннәргә кадәр булган тарихы турында. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Мәскәү Мәдәният департаменты ярдәме белән оештырылган әлеге күргәзмә быелның 30 мартына кадәр эшләячәк.










17 гыйнварда сәнгать фәннәре докторы Гүзәл Фоад кызы Вәлиева-Сөләйманова «Татарларның традицион тамбурлы чигүе – элмә» дигән онлайн-лекция уздырды. 18-19 гыйнварда Казан остасы Альбина Стоянова тамбурлы чигү буенча мастер-класс үткәрде. Шул ук көнне күргәзмә буенча кураторлык экскурсиясе дә булды.

Мастер-класста катнашучылар тукымада татар орнаменты элементын чигәргә өйрәнделәр һәм үз куллары белән башкарган эшләнмәләрне алып та киттеләр.

Шулай ук «Царицыно» Дәүләт музей-тыюлыгында 17-19 гыйнварда «Шәһәр һәм һөнәрләр: Казанда очрашу. Идел буе татарларының традицион сәнгате» күргәзмәсе эше кысаларында «Чигү остаханәсе: тамбурлы җөй» проекты булып узды.

**8-9 февральдә «Царицыно» музей-тыюлыгында уздырылган мастер-классларда катнашучылар гарәп каллиграфиясе остаханәсендә каллиграф кораллары, гарәп хәрефләрен бер-берсенә бәйләп язу төрләре белән таныштылар һәм борынгы куфа язу стилен өйрәнделәр. Дәресне оста Гөлназ Исмәгыйлева уздырды.**

**Ә 21-23 мартта «Чигү остаханәсе: элмәкле аппликация» дәресләрендә оста Альбина Стоянова белән бергәләп, татарларның үзенчәлекле бизәкләү техникасын өйрәнделәр, брошка җыеп, аны сәйләннәр һәм энҗе бөртекләре белән бизәделәр.**

# «Уникаль Россия» күргәзмәсендә Татарстан Республикасы экспозициясе эшләде



**2025 елның 23 гыйнвар – 9 февраль көннәрендә Мәскәүнең Кунак йортында V «Уникаль Россия» сәнгать-сәнәгать юбилей форум-күргәзмәсе эшләде. Күргәзмә кунакларына бөтен Россия традицион сәнгать әсәрләре, шулай ук БРИКС илләре осталары эшләре белән танышу мөмкинлеге туды.**

2025 елда илебезнең этномәдәни күптөрлелеге тәкъдим ителгән форум-күргәзмәдә Россиянең 70тән артык регионыннан 4000ләп оста катнашты. 102 чара һәм 50дән артык махсус проектлар уздырылды, алар арасында мастер-класслар, концертлар һәм башкалар бар иде.

«Уникаль Россия»нең милли экспозицияләре ел саен кызыклырак һәм күптөрлерәк була бара. Калуга, Иркутск, Калининград, Вологда, Волгоград өлкәләре, Татарстан, Бурятия, Кырым республикалары, Донецк Халык Республикасы һәм күп кенә башка регионнар Россия халкына һәм чит ил кунакларына илебезнең үзенчәлекле якларын күрсәттеләр.

Форумны оештыручылар әйтүенчә, быелгы экспозиция Россия Сынау палатасының – 325 еллыгына, шулай ук Париждагы күргәзмәнең – 125, Санкт-Петербургтагы Мануфактура күргәзмәсенең – 155, рус матрешкасының – 135,



Федоскино лак миниатюрасының – 230, Жостов декоратив бизәк фабрикасының 200 еллыгына багышланды. Ә иң зур юбилей, билгеле, Бөек Җиңүнең 80 еллыгы иде.

Россия башка илләрнең һәм халыкларның традицион милли мәдәниятенә һәрвакыт ачык булып калуы белән уникаль. Нәкъ менә шуңа күрә дә соңгы ике елда «Уникаль Россия» күргәзмәсендә дуслык илләре дә катнашты. 2025 елда биредә Һиндстан, Шри-Ланка, Бангладеш, Никарагуа осталары эшләрен күрергә мөмкин булды.





4 февральдән «Уникаль Россия» сәнгать-сәнәгать юбилей форум-күргәзмәсендә Татарстан Республикасы да тәкъдим ителде. Татарстан экспозициясе кысаларында «Гүзәллек», «BURO BANU», «IDEL», «Сәхтиан», «TatarScarf», «Презент» ПКФ, «Яратам» ҖЧҖ, «Алексеевск сәнгать туку фабрикасы» ҖЧҖ, «Бөек ефәк юлы» ҖЧҖ, Казан халык сәнгать һөнәрләре техникумы, Н. Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесы брендлары, шулай ук халык сәнгать һөнәрләре осталары Альбина Стоянова, Татьяна Табакова, Ольга Смирнова, Наталья Уразгильдина, Елена Флюр эшләнмәләрен күрергә мөмкин иде.



Татарстан Республикасы экспозициясе көннәрендә мастер-класслар тәкъдим ителде, Республикабыз этнодизайнерларының яңа коллекцияләре күрсәтелде.

Н.Пилюгина фоторәсемнәре

# Халык сәнгате һөнәрләре проблемаларына багышланган семинар

**2025 елның 27-28 февралендә Әлмәт креатив процесслар фабрикасында «Халык сәнгате һөнәрләре һәм декоратив-гамәли сәнгать: тарих һәм хәзерге заман» дигән семинар булды.**

Ул «Һөнәр» остазлык мәктәбе проектын гамәлгә ашыру кысаларында «Татнефть» хәйрия фонды һәм проектның рәсми партнерлары – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге ярдәме белән уздырылды. Проектның авторы – «Мәдәни үсеш үзәге: Ямаширмә авылы татарларының кулдан ясалган милли эшләнмәләре» һөнәрләре остаханәсе (җитәкчесе – Суфия Хәйбрахманова).

Әлеге чарага Татарстанның Әлмәт, Чирмешән, Баулы, Бөгелмә, Зәй, Минзәлә, Мөслим, Сарман, Ютазы, Әлки, Актаныш районнарыннан һәм Яр Чаллы шәһәреннән 100дән артык катнашучы килде. Алар «Татарстанның Кама аръягы регионы халык сәнгате һөнәрләре осталарының мәдәни үсеше үзәге»нең халык сәнгате һөнәрләре һәм декоратив-гамәли иҗат эшләнмәләре күргәзмәсе; рәссам, модельер, татарларның күн мозаикасы остасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Светлана Гарбузова хезмәтләре күргәзмәсе белән таныштылар, «Һөнәр» остазлык мәктәбенең фәнни җитәкчесе, сәнгать фәннәре докторы, Татарстан мәдәният үзәге фәнни хезмәткәре Гүзәл Вәлиева-Сөләймановaның лекциясен тыңладылар.









Семинар кысаларында Россия Мәдәният министрлыгының В.Д. Поленов исемендәге Россия дәүләт халык иҗаты йорты белән бергәлектә матди булмаган этномәдәни казанышлар объектларын өйрәнү кысаларында төшерелгән «Казан җөе» фильмын презентацияләү һәм карау үткәрелде.





Шулай ук Әлмәт креатив процесслар фабрикасында «Кама аръягы регионында халык сәнгате промыселлары һәм һөнәрләренең торышы һәм үсеше проблемалары» дигән түгәрәк өстәл уздырылды. Анда катнашучылар үз тәҗрибәләре белән уртаклаштылар, традицион промыселлар һәм һөнәрләрне саклауның әһәмияте, әлеге регионда яшәп килүче төрле промыселларны үстерү юллары турында сөйләделәр. Сессиянең модераторы Татарстан мәдәният үзәгенең фән һәм нәшрият эшләре буенча директор урынбасары Гөлназ Латыйпова иде. Түгәрәк өстәл эшендә үзәк хезмәткәрләре – сынлы һәм декоратив-гамәли сәнгать секторы мөдире Люция Низамиева һәм традицион мәдәниятны тикшерү һәм саклау бүлегенең фәнни хезмәткәре, сәнгать фәннәре белгече Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова да катнашты. Ике көнлек семинар эшкә йомгак ясау һәм чарада катнашучыларга сертификат тапшыру белән тәмамланды.

Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Тирмә – киез йорт

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова,**
*сәнгать фәннәре докторы,*
*Татарстанның атказанган*
*фән эшлеклесе*

**Казанның Иске Татар бистәсе территориясендә гадәти булмаган объект – шәһәр халкын һәм башкалабыз кунакларын татарларның тарихи үткәненә кайтара торган киез йорт – тирмә пәйда булды. Моннан мең еллар элек юрта борынгы төрки халыкның төп торак төре булган, ул татарларның төрки бабалары – Идел буе болгарлары белән бергә Урта Идел буе территориясендә барлыкка килгән, язма чыганаклар һәм археология материаллары шуны раслый.**

Бу проектның идеясе һәм аны гәүдәләндерү шәхси эшмәкәр Марат Рамазановның гомумтөрки мираска мөрәҗәгать итеп башкарылган эшчәнлеге нәтиҗәсендә гамәлгә ашты. Әлеге юрта кайчандыр күчмә тормыш алып барган борынгы бабаларыбызның яшәү рәвешен күз алдына китерергә ярдәм итә. Юртаны болгар һәм татар орнаментлары белән бизәү – сәнгать фәннәре докторы Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова һәм Казан дизайнеры Энже Кыямова тарафыннан тормышка ашырылды.

Моның өчен Ф.Х. Вәлиевның «Татарстанның борынгы сәнгате» һәм «Татар халык бизәге» исемле монографиясендәге рәсемнәр һәм фәнни материаллар файдаланылды. Юртаның әйләнә-тирәсендә татарларның реконструкцияләнгән иске музыка кораллары – шөлдерле барабан, кыл кубыз һәм кубыз (музыка кораллары ясау остасы һәм декоратор Марат Ханбеков эше), Г. Вәлиева-Сөләймmanagerованың фәнни ярдәмендә модельер Элара Шәйхи (Бюро Бану)





сәнгатьчә кабат торгызган Урта гасырлардагы ир һәм хатын-кыз киемнәре урын алды.

Казан үзәгендә урнашкан Иске татар бистәсе – тарихи үткәнебез белән хәзерге заман бергә үрелгән территория. Башкалабызның мең еллык тарихы татарларның борынгы бабалары – шәһәребезгә нигез салган Идел буе болгарларына барып тоташа. Иске Татар бистәсенең бер почмагында аларның мирасын кабат торгызу тәрки һәм татар мәдәниятенең тирән тамырларын ача һәм халыкның борынгы Казан тарихы белән кызыксынуын канәгатьләндерә. XVIII йөз ахырыннан берникадәр сакланып калган тирмә-юрта Каюм Насыйри урамындагы йортлар арасында урын алды. Юрта бистәнең тарихи йөзен бозмый, чөнки ул биек койма артына урнаштырылган, аның үзенчәлекле орнамент үрнәкләре белән бизәлгән өске өлеше генә күренеп тора. Бизәкләр VIII-XII гасырларда яшәгән Идел буе болгарлары сәнгатенә караган археология материаллары буенча торгызылды.

**Киез йортны күчмә торак итеп файдалану традицияләре Урта Идел буе территориясендәге беренче феодаль дәүләт – Идел буе Болгарстанын төзегән болгар халкыннан мирас булып калган. Археологик эзләнүләр һәм Урта гасырларның язма чыганаклары күрсәткәнчә, борынгы бабаларыбыз, утрак тормышка күчкәч тә, әлеге традицияне саклап, стационар йортлары янына тирмәләр салып куя торган булганнар. Урта гасырларның гарәп чыганаклары буенча да болгарларның тирмәне күчмә торак итеп файдаланулары мәгълүм.**

Сәяхәтче Әл-Истархи Болгар һәм Сувар шәһәрләре турында болай дип язган: «...аларның агач корылмалары бар, анда кышын салкыннан саклаңалар, ә җәен чатырларда яшиләр».

Алтын Урда ханнарының бик шәп тирмәләре һәм чатырлары булуы, шулай ук Казан ханлыгында яшәүчеләрнең тирмәне җәйге торак итеп файдаланулары турында да мәгълүматлар бар. Аерым алганда, рус елъязмаларында да Хан болынында (чама белән Болак ермагы территориясендә) урнашкан татар чатырлары турында телгә алына. Кышын – җылытыла торган бүрәнә йортларда, ә җәен көтүлектә яисә далада урнашкан күчмә тирмәләрдә яшәү гадәте шактый озак сакланган. «Юрта» сүзе төрки халыкларның йорт сүзеннән алынган булу ихтималы зур.

**XIX гасырда Карл Фукс та Казан татарларының Сабантуй бәйрәме вакытында күчмә тирмәләрдән файдалануы турында яза. Этнограф Н.И. Воробьев үзенең «Казан татарлары» дигән фәнни хезмәтендә (Казан, 1953) Иске Татар бистәсендә яшәүче таза тормышлы татарларның XIX гасыр азакларына кадәр җәен шәһәр читендәге тирмәләрдә яшәвен искә ала.**

Традицион татар торагын планлаштыруда төркиләрнең күчмә йортына хас булган кайбер үзенчәлекләр сакланган. Мәсәлән, элгәреге болгар торулыклары урынында (VIII-IX гасырлар) киез йорттагы кебек үк уртасына учак урнаштырылган стационар торак калдыклары табылган. Соңрак учакны балчыктан салынган мичләр алыштырган. Ул татар йортының эчке өлешен бүлеп торган. Киез йорттагы кебек үк, ишектән кергәч уң якта, мич янәшәсендә хатын-кызлар ягы урнашкан. Ир-атлар ягы түрдә – йортның дәрәҗәле урта өлешендә булган.

Киез йорт бизәлешендә архитектура киңлеге һәм символлы-мәгънәви эчтәлекнең үзара бәйләнеше чагыла.

Борыңгы төрки халыкларының фольклорында сурәтләнгәнчә, киез йорт төзелешендә Галәм, күк гөмбәзе үрнәкләре, шулай ук дөнья төзелешен чагылдыруны символлаштыручы предметлар – үк, агач багана (аскы һәм өске дөньяны тоташтыручы вертикаль көчләр), ярым түгәрәк казан (әйләндереп капланган юрта сурәте) һәм башкалар урын алган.

Йортның эчке өлеше билгеле бер система буенча бүленгән. Аның көнчыгыш ягындагы ишегеннән кергәч, түрдә – көнбатыш ягындагы дәрәҗәле урын хуҗа кешенеке булып исәпләнгән. Уң якта (төньякта) – хатын-кызлар, сулда (көньякта) ир-атлар ягы урнашкан. Мондый бүленеш йортның бизәлешендә дә чагылыш тапкан.

Киез йортны салу йола булып исәпләнгән. Башта моның өчен урын сайлап алганнар, булачак торакның үзеген билгеләгәннәр. Аннары тирмәнең нигез урынына түгәрәк сызганнар. Ишек кысасы ясап, аңа канат дип аталган рәшәткәдән ясалган дивар бауларын беркеткәннәр, тирмәнең каркасын корганнар һәм агач конструкцияне урнаштырганнар, соңыннан корылманы киез белән япканнар.

Тирмәнең уртасына учак ягу өчен өч таш яисә казан утыртылган өчаяк куйганнар. Казан нәсел символы булып саналган, һәм аны һәркем үзенчә бизәгән. Мәсәлән, Татарстан территориясендә табылган, Гун кабиләләре чорына караган казаннар шул хакта сөйли.

Тирмәне бизәүдә файдаланылган орнамент темаларының бөтен комплексы диярлек нигездә элгәреге болгар һәм монголларга кадәрге чорга (VIII-XII гасырлар) карый торган үрнәкләрдән алынган. Бигрәк тә бу тирмәнең алгы ягында чагыла, аның аскы һәм өске өлешендә бизәкле каймалар урын алган. Тирмәне уратып алган бизәкле кашага орнаментның кабатланып килүче төп элементыннан – тәкә мөгезе рәвешендәге бизәктән тора. Ул үндырышлылык һәм



*«ЮРТА» СҮЗЕ ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ЙОРТ СҮЗЕННӘН АЛЫНГАН БУЛУ ИХТИМАЛЫ ЗУР*





нәсел дәвамы символы булып санала. Мөгез өстендәге бадәм формасындагы орлык шулай ук әлеге символны ассызыклый. Ул болгарларның игенчелек культурасы белән бәйле традициясен дә чагылдыра. Нәсел дәвамы символикасы аскы кашага бизәгендә дә үсеш алган, ул эчендә орлыгы булган һәм беренче яфраклары чыга башлаган үрентенең дулкынсыман композициясе рәвешендә сурәтләнгән.

Тирмә интерьерында шулай ук болгар сәнгате мирасыннан алынган бизәк үрнәкләре комплексы да файдаланылган. Аны урап алган өске кашага ике юл тасмадан тора; аскы тасмадагы бизәкләр нәсел дәвамы символикасын кабатлый; өске тасма орнаментның төп элементы – лотоссыман (төркиләрдә нилүфар чәчәге) пальма яфрагы рәвешендә бизәлгән, ул татар һәм болгар орнаментларының иң борынгы үрнәкләреннән санала. Аның тамырлары татарларның Азиядә яшәгән бабалары сәнгатенә барып тоташа. Мәңге яшел пальма агачы озын гомерлелек һәм иминлек символы булып тора. Кыргызстан осталарының чыптада чиа камышыннан үреп ясаган орнаменты юртага керү ишеге өстендәге стенаны бизәп тора. Ул турыпочмаклы формага урнаштырылып, күзгеле композиция хасил итә. Анда йөрәк рәвешендәге бизәк формасы лалә чәчәгенә охшаган үрнәк белән чиратлашып килә, әлеге композиция өстән дә, астан да тукранбаш – өч яфраклы үсемлек белән тәгәлләнә. Өч өлештән торган бизәк символик рәвештә тормыш дәрәҗәсенең вертикаль күчәрен чагылдыра: нигез (борынгы бабаларыбыз), хәзерге заман һәм киләчәк. Бизәкнең мәгънәсе нәсел, гаилә, аның традицияләре, торак һәм аның табигать тирәлегендәге һәм галәм дөньясындагы урыны белән бәйләнгән.

Тирмә интерьерында үзәк урынны бизәкле киез келәм алып тора, аның уртасына учак урнаштырылган. Келәмнең стильләштерелгән бизәге бер төрле алты өлештән торган композицияне тәшкил итә.

Орнамент символик рәвештә җимеш бирүче, уртасы чәчәккә күмелгән (учак) мәңге яшел бакча темасын яктырта, ул нәсел һәм гаилә символы булып тора. Учак тирәсендәге түгәрәк бизәк Кояшны – Җирдәге тормыш һәм иминлек символын чагылдыра.

Ул Кояш алты почмаклы фигура эченә урнаштырылган, аның кырларында лалә чәчәге үрнәкләре урын алган. Лалә иртә язда чәчәк ата, татар халкы орнаментында ул элек-электән табигатьнең уянуы, мәхәббәт, гаилә бәхете һәм матурлык символы булып саналган. Өч почмаклы фигураның почмаклары, формасы буенча тәнбоекны хәтерләтүче, чәчәк таҗлары белән үрелгән. Алар бөгелмәле әләктергечләр белән баетылган ярым түгәрәкләргә урнаштырылган. Түгәрәкләр тоташкан урыннарда очып баручы кош үрнәкләре алгы планга куелган. Келәмнең бөтен бизәге күңеллелеге белән аерылып тора.





Тирмәнең агач ишегенә келәм бизәге стиленә туры килә торган орнамент төшерелгән. Аның симметрияле композициясе ишекнең ике яртысы тоташкан урынның уртасында һәм аның дүрт почмагына урнашкан. Төп бизәкләр – борылмалы үрентедән үсеп чыккан лалә чәчәге һәм өч таҗлы чәчәк үрнәкләре. Ишеккә эленгән кайтарып куела торган чаршау турыпочмаклы бизәк белән каймаланган, уртасына чәчәк түгәрәге «урнаштырылган». Алты өлештән торган өч таҗлы чәчәк бизәкләре шартлы рәвештә Кояш нурларын символлаштыручы түгәрәк эченә кертелгән. Композиция уртасына урнаштырылган Кояш тирәсендә бөгелгән сабак рәвешендәге бизәк урын алган, анда сабакның яфрак яруы һәм чәчәк атуы сурәтләнгән.

Җылылык чыганагы һәм Җиргә тормыш бүләк итүче, уңдырышлылык һәм иминлек символы булып саналган Кояш үрнәге төп тема булып тора.

**Юрта эчендә борынгы традицион җиһазлар урын алган. Агачтан эшләнгән бизәкле сандыклар һәм стенага эленгән киез капчыклар (бирнә букчалары) кәләш өчен әзерләнгән һәм кияү йортында сакланган. Букчаларның орнаментларында борынгы болгар һәм төрки халыкларының тормышы символлаштырыла. Хатын-кыз варианты буларак тудырылган беренче үрнәктә канатларын як-якка җәйгән ике башлы кош сурәте тәкъдим ителгән.**



Традицион рәсемнәрдә кошның төрле якка карап торган ике башы бер бизәк эчендә тоташтырылган, ә әлеге рәсемдә башлар бер-берсеннән берникадәр ераклыкта урнаштырылган һәм бер-берсенә карап тора. Моның мәгънәсе җиңел аңлашыла: гаилә – бер гәүдә, анда ир белән хатын тату һәм яратышып яши.

Кошлар өстендә борылмалы-сыгылмалы бөтеркәләре (иминлек яктысы) белән Кояш сурәтләнгән. Композициянең түбәнге сызыгында нәсел агачын символлаштыручы лотоссыман пальма яфрагы урын алган.

Икенче букчаның бизәкләре ирләр нәселе символикасын аңлатучы композицияне чагылдыра. Беренчедән, композиция уртасында тәкә мөгезләре үрнәген – ир-ат гаилә башлыгы булган күчмә культура билгеләрен күрәбез. Борынгы ышанулар буенча, тәкә мөгезләрен сурәтләү нәселне дәвам итүне, аның тормыш көчен һәм иминлеген белдерә. Шартлы рәвештә җир өслеге булып торучы аскы сызыктан «нәсел агачы» үсеп чыгып килә. Хатын-кыз букчасыннан аермалы буларак, биредә «нәсел агачы» гына түгел, универсаль «дөнья агачы» сурәтләнгән, аның өстендәге, борынгы кешеләр күзаллавына туры китереп эшләнгән, Кояш һәм Ай сурәтләре шул хакта сөйли. Дөнья агачының як-ягына, чиксез иҗат символы буларак, дулкынсыман бизәкләр үсеп чыккан.

Сандык – тирмә эчендә һичшиксез булырга тиешле җиһаз. Анда хуҗаларның әһәмиятле һәм кадерле әйберләре сакланган, татарлар йортында ул буыннан-буынга тапшырылып килүче истәлекле җиһаз булып саналган. Сандык яшел сабак һәм аннан үсеп чыгып, як-якка таралып киткән үрентеләр һәм лотоссыман (нилүфарсыман) чәчәк белән бизәлгән. Дулкынсыман сабак, үрентеләр һәм үрмәле үләннәр борынгы болгар орнаментына хас, Кояш темасы белән берррәттән, әлеге орнамент мәңгелек тормыш хәрәкәте символы булып тора. Ул – Идел буе болгарларыннан калган декоратив сәнгатьнең барлык төрләрендә дә чагылыш таба торган иң үзенчәлекле бизәк. Сандык өслегенең уртасындагы







*Г. ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ ФӘННИ ЯРДӘМЕНДӘ МОДЕЛЬЕР ЭЛАРА ШӘЙХИ (БЮРО БАНУ) СӘНГАТЬЧӘ КАБАТ ТОРГЫЗГАН УРТА ГАСЫРЛАРДАГЫ ИР ҺӘМ ХАТЫН-КЫЗ КИЕМНӘРЕ УРЫН АЛДЫ*

сырлап ясалган өч өлешле орнамент тирмәне бизәгәндә файдаланылган үрнәкләргә туры килә. Аның үзәк өлешендәге лотоссыман (нилуфарсыман) пальма яфрагы йөрәк рәвешендәге форма эченә урнаштырылган һәм ике яктан да үрентеләр белән «ныгытылган». Әлеге композициянең символикасы ачык: лотос – мәхәббәт, һәм озын гомерлелек чәчәге; Азия пальмасы шулай ук мәңгелек бәхетле тормышны һәм иминлекне символлаштыра. Юртада һичшиксез урын алырга тиешле җиһаз буларак, сандыкка иң изге һәм кадерле мәгънә салынуы гаҗәп түгел.

Утыру өчен билгеләнгән түшәк, юрган, мендәр, ястык кебек предметлар да символик эчтәлеккә ия. Бирегә килгән кунакларны гадәттә идәнгә утырткannar, шуңа күрә бу йомшак җиһазлар – һичшиксез булырга тиешле атрибутлар. Квадрат формалы ястыкларга дүрт һәм алты өлешле симметрик композицияләрдән торган бизәкләр төшерелгән: кайберләрендә – лалә һәм өч таҗлы чәчәк үрнәкләре, икенчеләрендә – лалә чәчәге һәм тәкә мөгезе үрнәкләренең тәңгәллеге, аларның барысының да уртасындагы бизәк кояшлы розетка рәвешендә тәкъдим ителә. Шулай итеп, юрта бизәкләре Идел буе болгарларының борынгы күчмә тормышы традицияләрен орнамент теле аша чагылдыра.

Тирмәнең конструкциясе һәм формасы меңнәрчә еллар дәвамында сакланып килгән. Әмма борынгы татарлар утрак тормышка күчкәннән һәм Ислам динен кабул иткәннән соң, күп кенә болгар орнаментлары онытылган, шулай да татар сәнгатендә гадәттә стильләшкән формада алар йола башкаруда файдаланыла торган предметларда сакланып калган. Бүген дә болгар һәм татар орнаментларының үзенчәлеге дала күчмә һәм утрак игенчелек культураларын берләштерү үрнәкләре булып тора.

# Мәчти авылы кымызчылары

**Халидә Баһаветдинова,**
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәре*

**1920 елларда Уфа губернасы Минзәлә өязе Байсар волостенә (хәзерге Актаныш районы) кергән Мәчти (икенче исеме Наратлы) авылы 1976 елларда юкка чыккан. Бу авылны – «морза Солтановлар авылы» дип тә йөрткәннәр.**



**Мәчти авылындагы Солтановлар гаиләсе йорты. 1895 ел**
**Электрон ресурс. Керү режимы: https://photo.miras.info/themes/istoriceskie-zdaniya?photo_index=807**



2021 елда, Актаныш районы авыллары тарихын өйрәнгәндә, без Мәчтидә экспедициядә булган идек. Ташландык йорт урыннары кайчандыр утар булганлыгын хәтерләткәнлеге истә калган.

Сөн елгасына коя торган бормаланып аккан Сикия елгасының сул ярында урнашкан авыл булган ул. Табигате матур, бүгенге көндә биредә төз наратлар гына шаулап утыра. Күрәсең, авылның икенче исеме шушы наратлар белән бәйледер.

Агыйдел елгасындагы Әҗәкүл пристаненнән 35-40 чакрым ераклыкта урнашкан Мәчти авылында XIX йөздән алып революциягә кадәр морза Солтановлар кымыз җитештерү белән кәсепчелек иткән. Авыруларны кабул итү өчен алар аерым биналар төзегәннәр, кымыз ясау өчен махсус атлары, ял итү өчен наратлы олы бакчалары булган. 1873 елларда Мөхәммәтшәриф, Шәйхелислам һәм Ишморат Солтановлар токымлы атларын Минзәлә ярминкәсендә яисә үзләренең заводларыннан 100 сумнан 300 сумга кадәр бәһа белән сатканнар.

Соңрак авыл крестьяннары да үз йортларындагы бүлмәләрне, дәваланырга килүчеләргә тапшырып, акча эшләгәннәр. Әзер кымызны Солтановлардан сатып алганнар. «Шәхси фатирларда кымыз эчү» медицина өлкәсенә яңа дәвалау төре булып килеп кергән.

Гомумән, XIX йөз ахыры – XX йөз башында Уфа губернасы өязләрендә кымыз җитештерү һәм аның белән дәвалау шактый киң таралган була. Халык медицинасында кымыз белән дәвалану тарихы борынгы чорларга барып тоташа. Аның шифасы турында беренче мәгълүматлар атаклы галим, фәлсәфәче һәм табиб Ибн Сина язмаларыннан күренә. Алтын Урда чорында хан сарайларында рус илчеләрен кымыз белән сыйлаганнар.

***Сәяхәтче Рубрикис һәм Марко Пололар үзләренең хезмәтләрендә кымыз ясау ысулларын, тәмен һәм кешегә ничек тәэсир итүе турында язып калдырганнар. XVIII йөз башында немец галиме П.С. Паллас кымыз эчәргә килүчеләр турында: «Московии и Дону недужный люд для питья кумыса, так как оный большую пользу в себе для здоровья имеет», – дип искә ала.***

(Карнаухов М.Н. Кумысолечение в Башкирии. – Уфа: Башгосиздат, 1948. – С. 3-4.).

Кымызның сәламәтлеккә файдасы һәм дәвалану үзәкләре турындагы белешмә аеруча XIX йөздә тарала башлый. Кымыз – бия сөтен әчетеп ясалган эчемлек. Җитештерү сере буыннан-буынга тапшырыла. XIX йөздә журналларда кымыз белән дәвалау методларын хуплап язган бәяләмәләр басылып чыга башлый. 1858 елда, Самара шәһәре янында, табиб Нестор Васильевич Постниковның шифаханәсе ачыла. Ул беренчеләрдән булып кымыз белән дәвалауга җитди игътибар бирә һәм фәнни өйрәнүгә керешә.

Шифалы эчемлек белән рус язучылары Л.Н. Толстой, А.П. Чехов, А.М. Горький, С.Т. Аксаковның энисе Мария Николаевналар, рәссам В.И. Суриков һәм башкалар дәваланган. Татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукайның да, мулла Габдрахман Рахманкулов ярдәме

белән, Троицк янындагы далада дәваланганы билгеле.

XIX йөз ахыры – XX йөз башларында Россиянең уналты губернасында һәм өлкәләрендә, хәтта дала халыклары арасында да, тулы бер кымызчылар челтәре барлыкка килә. Әмма эшмәкәрләрнең табыш артыннан куулары Н.В. Постниковның матур башлангычын юкка чыгара. «Кымызчылар» курортлардан тыш, авылларда сыену урыны эзләргә мәҗбүр булалар. Шәхси «шифаханәләрнең» гомуми күренеше һәм мәдәни-көнкүреш рәвеше күчмә халыкларның зур ныгытмасын хәтерләтә, санитар-табиб күзәтүеннән башка дәвалanulары күп очракларда сәламәтлеккә зыян гына китерә. Табиб анкетасы сорау-җавапларында, дәваланучыларның күбесе канәгать булмыйча, катгый рәвештә, «икенче мондый газапка башка килмәскә» дигән фикерләр дә очрый.

Бу тискәре күренешләрне бетерү өчен Уфа губернасы җир идарәсе (земство) кымызны һәм кымыз ясау биналарын күзәтү астына ала. Чыгарылган карарлар күрсәтелгән шифаханәләргә даими медицина күзәтүен таләп итә һәм савым бияләренә дә ветеринария хезмәте күрсәтүне билгели. Әлеге таләпләр, дәваланучыларга уңайсыз шартларны юкка чыгару гына түгел, җирле халыкны чахотка йоктырудан кисәтүне дә күздә тота.

XX йөз башында кымыз белән дәвалаучы санаторийларны тикшерү, авыллардагы яңа пунктларны ачыклау өчен Уфа губернасы җир идарәсе бүлеге медицина студентларын җәлеп итә: Уфа өязенә – И. Котлыбаев, Бәләбәй өязенә – Л. Лисовский, Минзәлә өязенә – И. Шамаев җибәрелә.

Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Мәчти авылында 1886 елда 7 хуҗалык кымызчылык кәсебе белән шөгыльләнә. Чәршәмбе көнне авылда базар була.

Укучыларны шул заманда хезмәт иткән табибларның истәлекләре белән таныштырып узасы килә.




**Кымыз ясау. Уфа губернасы, Дәүләкән авылы.**
Электрон ресурс. Керү режимы: https://en.wikipedia.org/wiki

Такталачык хастаханәсе җитәкчесе, врач А. Цареградскийның 1888 елның октябрь аенда земство җыелышында ясаган чыгышыннан (татарчага тәрҗемә – Х.Б.):

***«Такталачык бүлекчәсендә эшләгәндә, вазифам буенча һәм кайсыбер аерым кешеләрнең чакыруы белән, быел миңа кымыз белән дәвалау өлкәсендә билгеле авылда – Мәчтидә (Мастеево) булырга һәм бу эшнең торышы белән якыннан танышырга туры килде. Мәчтидә дәваланучыларның саны, шул сезонның иң кызган вакытында, уртача 80-120 кеше була; авыручылар арасында – ялыктыргыч канцелярия эше белән хәлдән тайган шәһәр хезмәткәрләре һәм чиновниклар, имтиханнардан арыган һәм аз канлылыктан җәфаланган укучылар. Мәчтигә нерв авырулары белән дә килүләр, шулай да үпкә авыруларыннан интегүчеләр процент ягыннан күбрәк, монда плевриттан (үпкә пәрдәсе ялкынсынуы) башлап, авыр туберкулезга кадәр, барысы да бар. Бу авыруларны аерым урнаштыру да, изоляция дә юк, киресенчә, әле генә чахоткалы кешедән бушаган бүлмәгә үпкәсе ялкынсынган яисә аз канлы авырулар урнаша. Дезинфекция дигән төшенчә бөтенләй юк. Гигиена тормыш тудырган шартлар белән бара. Кайбер хуҗалар 8 шешә кымыз эчертү шарты белән бүлмәләргә кертәләр. Теләсә теләмәсә дә, зарарлымы, файдалымы икәне белән дә исәпләшмичә, 8 шешә кымызны бер көн эчендә авыру эчәргә тиеш, башкача хуҗага акча керми. Минем үземә дә кымызны күп эчкәннән ашказаннары бозылган авыруларны күрергә туры килде. Кайберәүләр биредә хәлдән тая, тирли һәм салкын тидерә.***

***Еш кына Мәчтигә авырулар, белгечләр белән сөйләшмичә, биредә киңәш табуларына өметләнеп киләләр, ә таба алмагач, нинди кымыз, ничек һәм күпме эчәргә икәнен белмиләр, һәм башкалар. Нәтиҗәдә биредәге «мәрхәмәтле» күрше, яисә кымыз хуҗасы киңәше авыруга берничек тә ярдәм итә алмый.***

***Мәчтидәге кымыз белән дәвалау үзәге, гигиена һәм дезинфекция таләпләрен үтәмичә, табиблар тикшерүеннән башка, 2 елдан артык эшләп килә. Бу чорда күпме йогышлы авырулар таралуын, күпме аз канлылар, нерв авырулары, плеврит белән җәфаланучыларның артуын, чахотка элэктерүләрен күз алдына китерергә мөмкин.***

***Шушы хәлләрнең барысын да искә алып, кымыз белән дәвалау үзәгенең файдасына караганда зарары күбрәк булганга, аны бөтен медицина таләпләренә туры килерлек итеп үзгәртергә кирәк дип саныйм; минем фикеремчә, аның киләчәктә гамәлдә булуы бары шушы шартлар белән бәйле».***

(Из журнала XIV очередного Мензелинского уездного земского собрания с 11 по 18 окт. 1888 г. и доклады управы с приложениями к ним. – Казань, 1889. – С. 325-326).

Шундый чыгышлардан соң, хөкүмәт белән земство идарәсе бу өлкәдә үзгәрешләр кертергә омтыла.

1903-1906 елларда өяз җир идарәсе җәйге айларда табибларны яки өлкән курс студентларын чакыру юлы белән кымыз кәсебен тикшерүне, санитар күзәтүне дәвам итә. Моның өчен, 1904 елда – 1400 сум, 1905 елда – 1020 сум, 1906 елда – 900 сум акча бүленеп бирелә. Бу чыгымнар өяз җир идарәсе өчен күп була, һәм 1906 елда земство җыелышында, элеккеге тәртибен гамәлдән чыгарып, күзәтү участок табибларына йөкләнә.

Җирле губернатор тарафыннан хупланган курорт җыемы (налог) алу уйлап табыла. Җыем алу өяз земствосы тарафыннан кеше башына

ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...

1 сум, гаиләдән 3 сум күләмендә карала. Өч көннән артык яшәмәгән һәм 10 яшькә кадәрге балалар налогтан азат ителәләр.

Сезон беткәннән соң, табиб кымызчылар яшәгән барлык бүлмәләрнең дезинфекцияләнгән булуын тикшерә. Аңарга ярдәмгә медицина факультетының 4нче курсыннан ике студент чакыру күздә тотыла. Билгеләнгән фаразларны тормышка ашыру өчен күзәтүнең бәясе түбәндәгечә билгеләнә: санитария табибына 1 айга – 150 сум, 4 айга – 600 сум; ветеринария табибына 1 айга – 100 сум, 2 студентка – аена 100әр сум, барлыгы, дезинфекция чыгымнарын исәпләмичә, 1400 сум түләнергә тиеш була.

Җирле идарә мәгълүматларына караганда, өяздә җәй дәвамында кымыз белән 100дән дә ким булмаган гаилә һәм 1000 аерым кымызчы дәвалана. Димәк, курорт җыемы 1300 сум, ягъни күзәтүнең бәясен каплый торган сумма булырга мөмкин. Эчке эшләр министры бу проектны хуплый. Налог җыю, күп кенә хуҗаларның фатирларын тикшерү, төрле рәвештә халыкның каршылык күрсәтүен китереп чыгара.

Икенче язма чыганак – Түбән Новгородның мәшһүр табибы, туберкулез мәсьәләләре буенча белгеч, туган якны өйрәнүче галим В.Н. Золотницкийның 1914 елгы «Путеводитель кумысника. Подробное описание кумысолечебных санаторий, заведений и других мест Самарской, Уфимской, Оренбургской...» дигән белешмә хезмәтендә Мәчти авылы шифаханәләре турында болай язылган:

***«Монда дәваланырга килгән кымызчылар крестьян өйләрендә, башлыча, морза Солтановларда урнашалар. Алар өчен зур йорт һәм берничә флигель бирелгән. Биредә сезонга 150 кымызчы дәвалана һәм аларның 50дән артыгы Солтановларга урнаша. Кымызчыларның төп контингентын укытучылар тәшкил итә. Бүлмәләр тәртиптә, кирәкле җиһазлар һәм ятаклар белән тәэмин ителгән. Дәваланучылар еш кына үз урын-җирләре белән киләләр. Фатирларның бәясе аена 8-15 сум.***

***Уңайлылык өчен килешү буенча түләнә: 2 ашамлыктан торган төшке аш һәм көненә 2 тапкыр сөт һәм ак ипи белән чәй уртача – 15 сум, ә 1 ашамлык белән – 20 сум тора. Өстәл мактанырлык түгел, чисталык җитеп бетми, һәм ит ризыкларыннан, бары тик сарык ите генә бирелә, сыйфаты югары. Кымыз 3 хуҗалыкта җитештерелә, иң яхшы сыйфатлысы – Гөлчирә Солтанова хуҗалыгында. Кымыз бәясе – 15 тиен. Әмма көнгә кимендә 6 шешә алсаң гына ташлама ясала.***

***Медицина ярдәме булмау җитди җитешсезлек булып тора. Земство участок табибы моннан 25 чакрымдагы Пучы авылында яши. Ә фельдшерлык пункты 6 чакрым ераклыкта, почта бүлекчәсе, зур татар базары булган Байсар авылында урнашкан. Корреспонденция атнага 2 тапкыр Камадан һәм Уфадан килеп тора. Ат яллап Байсарга бару өчен 30 тиен түләргә кирәк.***

***Чыгымнар якынча аена 45-50 сумга чыга (Мәчти авылы кымызчылары сүзләреннән язылган). Адрес – Байсар станциясе, Уфа губернасы, Гөлчирә Шаһиморат кызы Солтанова (Мәчти авылы)».***

*(Путеводитель кумысника. Подробное описание кумысолечебных санаторий, заведений и других мест Самарской, Уфимской, Оренбургской, а также и некоторых других В.Н. Золотницкий. – Нижний Новгород, 1910. – С. 101-103).*

Ике язма арасында 26 ел вакыт узса да, биредә дә медицина ярдәме җитәрлек дәрәҗәдә булмавы ачык күренә.






**Кымыз курортлары. Бия саву.** Электрон ресурс. Керү режимы: https://project2005v1.narod.ru/gallery/hystory.htm

**Минзәлә өязе кымызчылары. Студент-медик И. Шамаев хисабыннан. 1914 ел**

| | Һөнәр-ханә | Савым бияләре | Кымыз-чылар | Үпкә авы-рулары өчен | Шәхси йортлар-да | Ашханәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Минзәлә | 2 | 16 | 57 | 19 | – | – |
| Иштирәк (хәзерге Тукай районы) | 4 | 15 | 48 | 12 | 16 | 1 |
| Мәчти | 14 | 59 | 162 | 62 | 21 | 4 |
| **Барлыгы** | **20** | **90** | **267** | **93** | **37** | **5** |

Минзәлә өязендәге кымыз кәсебенең 60-80 процентын Мәчти авылы һөнәрчеләре тәшкил иткән. Дәваланучыларның күбесе урта хәлле кешеләр: табиблар, чиновниклар, укытучылар, студентлар, төрле сәүдәгәрләр, приказчиклар, авыл руханилары. Күбесе ашханәдә тукланган.

Гадәттә, дәвалану сезоны 15 майдан алып 15 августка, һава торышы яхшы булса, 1 сентябрьгә кадәр дә барган. Кымызның сыйфатына җәйләүдә үскән дала үләне, һава торышы, чиста итеп әзерләү һәм дөрес температурада саклау нык тәэсир иткән. Ул табиб яки хуҗа күзәтүе астында җәйләүдә берничә ысул белән мичкәләрдә яисә шешәләрдә җитештерелгән. Чагыштырып карау өчен, кымызның бер шешәсе Мәчти авылында 15 тиен йөрсә, Бәләбәй өязендә 10-25 тиенгә сатылган.

1914 елгы Беренче империалистик сугыш башлангач, кымыз сезоны гадәти вакыттан элек тәмамлана, кымызчылар июльнең икенче яртысында кайтып китәләр. Әмма сугыш булуга карамастан, кымыз җитештерү Мәчти авылында туктамый. 1915 елда кымыз җитешерү белән шөгыльләнүче Солтановлар нәселеннән 4 хуҗалык искә алына: Мөхәммәтсолтан Шаһимөхәммәт улы, Гөлчирә Шаһиморат кызы, Мөхәммәтгали Габделгалләм улы һәм Ширияздан Габделханнан улы Солтановлар.

# Мәзәкләрдә – күңел көрлеге

**Лилия Мөхәммәтҗанова,**
*филология фәннәре докторы, доцент, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре*

## Мәзәк – фольклор жанры

Башка эпик жанрлар белән бергә татар халык иҗатында мәзәкләр бик киң таралыш алган. Үзенең төп сыйфатлары белән ул «анекдот» сүзенең асыл мәгънәсенә якын тора. «Анекдот» – грек теле аша кергән атама, әүвәлдә «басылмаган», «басмага төшерелмәгән» дигәнне аңлаткан, халык иҗатының көлкеле тарихны бәян итә торган көтелмәгән чишелешкә ия үрнәге.

Мәзәкләр борынгы заманнарда ук туып, XIX йөзләрдән Россиядә төп хасияте көлке тудыруга нигезләнгән мөстәкыйль фольклор жанрына әверелгән. Борынгы чорлардан ук кулланылышта йөргән кечкенә күләмле бу төр иҗат әле безнең көннәрдә дә актив яши һәм үсә.

XX йөз башына кадәрге татар матбугатында мәзәкләр еш кына «хикәят» исеме белән басылып килгәннәр. Шулай ук «лэтифа», «мәзәк (мәзах)» атамалары да киң кулланылган. «Мәзәк» сүзе исә, жанр атамасы буларак, татар фольклорында гына очрый. Халык авыз иҗатының әлеге жанрга караган әсәрләре формалашып, камилләшкән, буыннан-буынга күчә барган, бу процесста халык язмышы, зур вакыйгалар, яшәү тирәлеге, рухи халәт, дини карашлар чагылыш тапкан.

Татарларның кайсы территориядә яшәвенә бәйле җирле үзенчәлекләр белән дә тыгыз үрелеп, бу ядкарьләр милли кодларны саклый торган гармоник бөтенне тәшкил итә.

## Күләгәдә сугышырбыз

Мәзәк дип ачык күренеп торган кульминацияле һәм көтелмәгән чишелешле бер эпизодка корылган сатирик яки юмористик эчтәлекле эпик әсәрне атыйлар. Бер генә сюжет сызыгы булган, тапкыр җаваплы кыска күләмле мәзәкләрнең ханнар-патшалар заманыннан ук килә торганнары бар. Мәсәлән, Бохара Әмиренә: «Быел Идел буенда иген уңмаган, халык бик ачыга, ачтан үлүчеләр дә күп», – дигән хәбәр җиткерәләр. Моңа каршы Әмир, гаҗәпләнеп, әйтә икән: «Ник ачтан үләләр, ник пылау ашамый икән соң алар?». Яисә, патшалардан берәү, сугышка хәзерләнгәч, гаскәр башлыкларыннан берсе килеп: «Әй, падишаһым, дошман гаскәре шулкадәр күп, һәрберсе берәр генә ук атса да бөтен күк йөзен капларлык», – ди икән. Моңа каршы патша болай дип җавап биргән: «Бигрәк яхшы, күләгәдә сугышырбыз», – дигән ди. Янә бер мәзәк: шулай бер заман патша үзенең күрәзәчесеннән сорый ди: «Мин кайчан үләрмен икән?». Күрәзәче моңа: «Бәйрәм көнне үләчәксең», –

дип җавап кайтарган. «Кайдан белдең?» – дигән сорауга күрәзәченең җавабы мондый булган: «Сез үлгән көн – зур бәйрәмнәрнең дә иң зурысы булачак».

Реаль чынбарлык белән тыгыз бәйләнгән кыска сюжетлы мәзәкләрдә еш кына мифик көчләр, әйтик, шүрәле, җен, фәрештә, шайтан һәм башкалар да чагылыш таба. Бу – мәзәк жанрының генезисы һәм үсеш эволюциясенә бәйле күренеш. Борынгы заман фольклорында мифлар белән бергә реаль эчтәлекле, тормышта булып узган хәл-вакыйгаларны бәян итүче көнкүреш хикәяләре һәм анекдотлар зур урын алып торган. Көнкүреш хикәяләренең борынгы чорлардан ук киң таралган аерым сюжетлары халык мәзәкләренең иң иске катламын тәшкил иткән. Мәсәлән, шайтан, әҗәл, фәрештәләр гәүдәләнеш тапкан, кешенең алар белән мөнәсәбәте хакында сөйләнә торган мәзәкләрне килеп чыгышы иң борынгы чорга карый торган мәзәкләр дип уйларга нигез бар. Аларның артык күп түгел, бөртекләп кенә санарлык булулары, ягъни озак вакыт үтү сәбәпле, әкренләп юкка чыга барулары да шул хакта сөйли. Мондый мәзәкләрнең булганнары асылда татарларда мөселманлык чорына карый, ислам мифологиясенә барып тоташа. Мәсәлән, шулай бер агайдан каберендә фәрештә сорау ала икән: «Хак боерыгын тоттыңмы?» – дип сорый ди.

**Бер генә сюжет сызыгы булган, тапкыр җаваплы кыска күләмле мәзәкләрнең ханнар-патшалар заманыннан ук килә торганнары бар. Мәсәлән, Бохара Әмиренә: «Быел Идел буенда иген уңмаган, халык бик ачыга, ачтан үлүчеләр дә күп», – дигән хәбәр җиткерәләр. Моңа каршы Әмир, гаҗәпләнеп, әйтә икән: «Ник ачтан үләләр, ник пылау ашамый икән соң алар?»**



Агай, сорауга туры җавап бирә алмый, ялгыш ишеткәнгә салышып, боргалана башлый: «Ат койрыгын? Тигәнәк ябышкан булса, ат койрыгын тотасың инде ул тигәнәген чүпләгәндә», – ди икән. Яисә авыр йөк күтәреп ташучы берәү: «Ичмасам, Әҗәл дә килми!» – дип зарлана ди. Шул вакыт моның каршына Әҗәл килеп баскан да: «Мине чакырган идеңме?» – ди икән. Тегенең бер дә үләсе килми, «Әйе, чакырган идем шул, әйдә, менә шушыны күтәрешеп кайт та, аннан үз юлыңа китәрсең», – дип хәйләгә керешкән.

Мәзәкләр һәрвакытта да бер эпизодтан гына тормый. Жанрның ике вакыйгага корылган үрнәкләре дә күп очрый. Бер вакыт Мәнди этисе белән базарга сыер алырга бара. Әтисе сыер буаз булсын дип бик каты сатулаша. Бу беренче вакыйгадан Мәнди буаз нәрсә яхшы була икән дигән нәтиҗәгә килә. Күпмедер вакыттан Мәндигә кыз яучылыйлар. Шунда инде Мәнди мәндилеген күрсәтә. Беренче вакыйганың нәтиҗәсен истә тотып, яучы карчык белән: «Миңа кыз да булсын, буаз да булсын!» – дип ярып сала.

Мәзәкләрнең хәтта өч вакыйганы эченә алганнары да була. Моның мисалларын күбрәк Хуҗа Насретдин турындагы мәзәкләр арасыннан табарга мөмкин. Борынгырак бер мәзәктә өч монах Хуҗага һәркайсы аерым-аерым өч сорау бирә: дөньяның уртасы кайда? Күктәге йолдызлар никадәр? Минем сакалымда ничә бөртек йон бар? Хуҗаның өч сорауга өч тапкыр җавабы – өч эпизодның бер мәзәккә берләшүе.

## Мәзәкнең дә үзәге бар

Мәзәкнең үзәге, аны мәзәк итүче нәрсә – акыллы, гыйбрәтле сүз, кайберләрендә афоризм булырдай оста, тапкыр әйтем, вакыйганың тыңлаучы һич көтмәгән чишелеше. Мәзәкнең бөтен яме-тәме, тәэсир көче аның ахырында. Текстта мәзәкнең «тозы» алдан хәбәр итеп куелса, ул чагында мәзәк үзе дә юкка чыгар иде. Әйтик, бер кеше төнлә урманга утын урларга баргач, сызгырган тавышлар ишеткән дә, урман каравылчысы сизде ахрысы дип, тизрәк өенә



чапкан. Кайтып җиткәч, тыңлап карый, тагын да шәбрәк сызгыралар. Хатынына әйткән: «Биклә капканы, кертмә урман каравылчысын!» – дигән. Үзе тиз генә идән астына төшеп яткан. Теге сызгырган тавыш һаман туктамый, монда да ишетелә икән. Хикмәт тегенең үз борыны сызгыруда булып чыккан.

Мәзәкләрнең көтелмәгән чишелеш белән тәмамлануы зарури шарт, шуңа бәйле, жанр поэтикасына махсус чаралар һәм алымнар килеп керә. Шуларның берсе – алогизм. Көтелмәгән чишелешне икенче төрле мәзәкнең гадәти булмаган ахыры дип тә әйтергә мөмкин. Ягъни, әсәрдә бәян ителгән вакыйга, ситуация белән мәзәк героеның үз-үзен тотышы арасында ярашмау, логикасызлык барлыкка килә. Алогизм бигрәк тә ахмак, беркатлы кешеләр турындагы мәзәкләргә хас. Мондый кеше тормыш күренешләренең асылына төшенә алмый, чын сәбәпне аңламыйча ялгыш нәтиҗәләр ясый. Шуңа күрә дә аның эшләре яки сүзләре тыңлаучылар өчен бөтенләй көтелмәгәнчә булып чыга.

Хәйрулла исемле бер кешенең кәҗәсен бүре ашый. Шуннан бу Арча базарына барып икенче кәҗә сатып ала. Кайткан вакытта кәҗәне

вагонга кертергә рөхсәт итмиләр һәм аптыраган Хәйрулла аны вагон артына бәйләп куя. Икенче станциядә төшеп караса – кәҗәнең башы гына асылынып тора икән. Моны күргәч, Хәйрулла, ачынып: «Каһәр суккан бүре! Поезд артыннан да куып җиткән бит», – дигән.

Моңа охшаш мисаллар Мәнди, Мокыт мәзәкләре арасында аеруча күп. Иртән озак йоклап олауга соңга калган Мәнди: «Әтәч кычкырмый таң атмый, шул кычкырып аттырган», – дип, бөтен гаепне әтәчкә аудара. Хатыны бала табарга җыенгач, Мокыт кендек әбисен ишек төбеннән борып куып җибәрә: «Теге юлы да хатынга кыз бала таптырттың, миңа ир бала кирәк, икенче кендек әбисе килсен»,– ди.

## Мәзәк – тел һәм күңел байлыгы

Мәзәкләрдә комик ситуация барлыкка китерүдә тел чаралары еш файдаланыла. Аларның нигезендә мәзәк героеның нинди дә булса сүзне яки тәгъбирне ялгыш аңлавы яки юри ялгыш аңлаган булып кылануы ята. Мәзәк хәл геройның тел белмәве, башка телдә әйтелгән сүзне аңламавы аркасында да килеп чыгарга мөмкин. Нәтиҗәдә ул я үзенә бирелгән сорауга һич көтелмәгән җавап кайтара, я эшлисе эшен җиренә җиткерә алмый көлкегә кала. Мәсәлән, бер агай авылдан шәһәргә он сатарга бара да, онын, сатмыйча, кире әйләнеп кайта. «Ник онынны кире алып кайттың, ник сатмадың», – дигән сорауга ул болай дип җавап бирә: «Әй, анда бөтенесе мука да мука ди, онны сорап та карамадылар, берәүгә дә он кирәк булмады», – ди.

Тел чараларыннан мәзәкләрдә сүз уйнату (каламбур) аеруча күп очрый. Ул аеруча мәгънәләре үзгә сүзләрнең бертөрле әйтелеше (омонимия) һәм бер сүзнең берничә мәгънә аңлатуы (полисемия) күренешләренә корыла. Яңгир (күрәсең, Җиһангир исеменнән үзгәргәндер) исемле бик ашамчак бер кияү, бабасына кунакка баргач, болдыр астына кача да, өеннән алып килгән азыкларны ашый башлый. Бу вакыт коеп яңгыр ява икән. Бабай белән әби болдырга чыгып: «СөбханАллаһ, яңгыр ишә генә!» – дип әйтүләре була, болдыр астындагы кияү: «Ишсә ни, үзенекен ишә ич!» – дип кычкыра. Монда «Яңгир» һәм «яңгыр» сүзләренең охшаш әйтелеше, шулай ук «ишү» сүзенең берничә мәгънә белдерүе, ягъни омонимия дә, полисемия дә файдаланылган.

Сүзне ялгыш аңлауга корылган мәзәкләрнең бер ишеләрендә герой чит телне белми һәм башка телдәге берәр сүзне аңа аваздаш булган татар сүзе дип кабул итү аркасында көлкеле һәм уңайсыз хәлдә кала. Мәсәлән, бер карт кечкенә чана белән тартып базарга он сатарга килә. Бер рус кешесе аңардан оны турында: «Ржаная или пшеничная?» – дип сорагач, бу ачуланып: «Ырҗаерсың да, пешегерсең дә, 70 чакрымнан тартып килеп кара!» – дип җавап кайтара.

Мәзәк геройлары еш кына күчерелмә мәгънәдәге сүзләрне (әйтик, фразеологизмнарны һәм башкаларны) туры мәгънәдә аңлап хур булалар. Бер кыз әнисенең гел «түгәрәк-түгәрәк сүзләр генә сөйлә» дигән нәсихәтен үтәп, егете белән очрашкач «шар», «көлчә», «тәгәрмәч» кебек сүзләр тезә башлый. Яисә, тел белмәү белән бәйле, чит телдәге охшаш яңгырашлы сүзләрнең мәгънәсен үз телендәге сүзгә якынайтып, бутап аңлау да мәзәк тууга сәбәп була ала. Мәсәлән, базарга килгәндә берәү юлда солы тутырылган капчык таба, хуҗасы табылмагач, аны сатып акча эшләргә уйлый. Капчыгын чишеп куюга, моннан русча: «Почём килограмм овса?» дип, солының бәясе белән кызыксыналар. Солы тапканымны сизгәннәр икән дип куркып калган сатучы: «Тапса ни булган? Таптым шул, урлап алмадым Аллаһыга шөкер, таптым» – дип җавап биргән ди.

Куелган сорауны яки кушылган йомышны тар мәгънәдә, сүзгә-сүз аңлау мөмкинлеге еш кына мәзәк геройларына үзләрен уңайсыз хәлдән чыгару, каршы якның дәлилләрен кире кагу чарасы булып хезмәт итә:

– Әй, малай! Син миңа сырага папирос башы салып китергәнсең!



– Ник? Ун тиенгә бөтенне салып китерер дип белдеңме әллә?

Сүзне төрлечә аңлауга нигезләнгән мәзәкләр арасында табышмакларга һәм аларга якын торган четерекле сорауларга җавап эзләтү формасында корылганнары да байтак. Табышмак үзе авыр булмый, өстәвенә аның җавабы да сиздереп куела. Ләкин җавап эзләүче, турысын аңлап, бөтенләй мәгънәсез җавап кайтара. Мәсәлән, Хуҗа Насретдинга: «Тышы ак, эче сары. Нәрсә икәнен белсәң, үзеңә тәбә пешереп ашатам», – дигән табышмак әйтәләр. Сүзнең йомырка хакында барганлыгы ачык. Ләкин Хуҗаның җавабы аңа якын да килми. «Белдем, белдем, шалканны уйганнар да, эченә зәгъфрән орлыгы тутырганнар», – ди ул. Бу очракта җавап эзләүченең томаналыгы, зиһенсезлеге көлкегә алына. Ә кайчакта табышмак әйтүче үзе көлкегә кала. Ул табышмак белән бергә ялгыш аның җавабын да әйтеп ташлый һәм, икенче кеше дөрес җавап биргәч, гаҗәпләнә. Элекке заманда ике теләнче бәхәсләшәләр. Берсе әйтә: «Минем капчыгымда ничә кабартма барлыгын белсәң, икесен дә сиңа бирәм», – ди. Тегесе, әлбәттә, «Ике!» дип җавап кайтара. Беренчесе, иптәшенең зирәклегенә хәйран калып, ике кабартманы да аңа бирә.

## Мәзәк гасырларны иңли

Мәзәктә диалогта катнашучыларның бер-берсен аңламавына һәм шуның нигезендә көлкеле ситуация тудыруга хезмәт итүче алымнарның берсе – кинаяле сөйләм. Аның төрле формалары бар. Әйтик, мәзәк герое берәр кыңгыр эш эшли һәм шуны үзе үк икърар итә. Әмма аның сөйләме тыштан бик шома була, ритмлы һәм рифмалы итеп корыла, текстка бер-берсенең мәгънәләрен юкка чыгара торган сүзләр (еш кына антонимнар) кертелә. Нәтиҗәдә, икенче герой, тышкы эффектка алданып, сөйләмнең асылына төшенә алмыйча кала. Мәсәлән, бер хатын уракка баргач, көне буе басуда йоклап кайта. Кайткач картының «күпме урдың?» дигән соравына каршы:

– Урып урмадым, карап тормадым, торып торна санамадым, өчәр-өчәр көлтә – өч өем көлтә урдым, – дип җавап бирә. Карты: «Әй

рәхмәт, карчык! Бик күп ургансың икән», – дип, хатынын мактый. Бу очракта мәзәк ялкау хатыннан бигрәк картның беркатлылыгыннан көлә.

Мәзәкләрдә сөйләнгән вакыйганың, бигрәк тә ахыргы өлешенең үткенлеген, җорлыгын, тапкырлыгын көчәйтү максатында такмак-такмазалар, мәкаль-әйтемнәр, янәшәлекләр, чагыштырулар, ирония, гипербола кебек тел-стиль һәм сурәт чаралары киң файдаланылу – халкыбызның тел дәрьясы никадәр мул икәнен дә раслаучы билге. Менә, мәсәлән, төп герое Җирән чичән булган борынгы мәзәктә атлар менеп сахрага йөрергә чыккан хан белән Җирән чичән турында сүз бара. Күз күне икән, халык телендә «пәри арбасы» дип йөртелгән тәгәри үләнен җил тәгәрәтеп алып бара ди. Ханның, Җирән чичәннең сүзгә тапкырлыгын сынийсы килеп: «Бар, шул тәгәрине куып җит тә сорашып бел, кая бара, кая туктарга уйлаганын», – ди. Чичән тәгәрәп барган үлән артыннан куып җиткән дә, кире борылып килеп, ханга түбәндәге җавапны әйткән:

– Сорый килгән син тинтәкме, сората җибәргән хан тинтәкме, күчәремне җил белә, кунарымны сай (уйсу җир) белә, – дип әйтте, дигән. Төрки халыклар өчен урта гасырлардан ук килүче уртак образ – Җирән чичәннең тапкыр җавабына нигезләнгәннәреннән алып, бүгенге көндә дә телгә осталыкны асыл билгесе итеп саклап калган татар мәзәкләре бар. Халкыбыз шигъри сүзсез, мәзәксез яшәми. Борынгы чорларны ук чагылдырган мәзәкләрнең хәзерге заманда яңадан-яңалары туып тора. Аларда халкыбызның иң асыл сыйфатлары – кунакчыллыгы, нәзакатьлелеге, һәр ситуациядән җиңел чыга белү осталыгы күренә. Гадәттә мәзәк кешеләрнең бер-берсе белән үзара сөйләшүе вакытында туа. Фәнни экспедициядә Самара өлкәсе Красный Мост авылында яшәүче Хәтимә Шәяхмәт кызы Вакказова (1941 елгы) белән әңгәмә барышында килеп туган, информантның оста җавабына нигезләнгән бер хикәят югарыда сөйләнгән Җирән чичән җавабыннан бер дә ким түгел. Хәтимә апага фольклор материалы җыю максаты белән килеп кердек. Халкыбыз кунакчыл, кайсы гына өйгә керсәң дә чәй тәкъдим итү гадәте яши. Хәтимә апа да табынга кыстый башлады. Үзе туктаусыз сөйли:

**Сүзне ялгыш аңлауга корылган мәзәкләрнең бер ишеләрендә герой чит телне белми һәм башка телдәге берәр сүзне аңа аваздаш булган татар сүзе дип кабул итү аркасында көлкеле һәм уңайсыз хәлдә кала. Мәсәлән, бер карт кечкенә чана белән тартып базарга он сатарга килә. Бер рус кешесе аңардан оны турында: «Ржаная или пшеничная?» – дип сорагач, бу ачуланып: «Ыржаерсың да, пешегерсең дә, 70 чакрымнан тартып килеп кара!» – дип җавап кайтара.**

– Иии, әйтеп килмәдегез бит менә, әйтеп килмәдегез! Бәлешләр пешереп торган булыр идек. Бәлешкә дигән итләрем дә әзерләп куелган. Тәмле итеп бәлешләр салган булыр идем! – дип өзгәләнә. Шунда безне информантларга озата йөргән җор телле Асия апа әйтә куйды:

– Болар бит әле бүген китмиләр, атна-ун көн торасылар. Хәтимә апа, мин әйтәм, иртәгә бәлешләреңне пешереп куясыңмы әллә дим? Киликме иртәгә?

Хуҗабикәнең:

– Ишек кискән, тәрәзә тишкән, килсәгез! – дигән җавабы теманы япты. Миңа калса, күз алдыбызда яхшы мәзәк туу үрнәге иде бу. Бу һәм башка мисаллар мәзәк һәм мәзәк хәлләрнең тормыш-көнкүрешебездә әле дә барлыкка килеп торуына дәлил. Халкыбызның көр күңеле боекмасын, күңел чишмәләре саекмасын, мәзәкләрендә яхшы кәефе, зирәк акылы, мул тормыш-көнкүреше чагылып торсын!

**Рәсемнәрдә: ТФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Самара, Чиләбе өлкәләренә, Мөслим районына оештырган экспедиция вакытында.**

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**

# Арбаулар



**Галимҗан Гыйльманов,**
*язучы, әдәбият белгече*

**Халык арасында да, фольклор фәнендә дә мифологиянең бер жанры буларак АРБАУЛАРга карата фикер төрлелеге күзәтелә. Нигездә ике төрле караш хакында сүз алып барырга мөмкин. Беренчел, яки борынгыдан килә торган караш: арбау ул – әфсенләү, сихерләү (русча: заговоры, заклинания).**

Ләкин әфсенләүнең бөтен төре дә арбауга керә алмый, бары тик җыр-такмак поэтикасына корылган һәм теләк рәвешендә бирелгән вариантлары гына арбау була ала. Икенче караш: туй җырларының бер төре арбау атамасы белән белдерелә: киленне арбау, кияүне арбау, яшьләрне арбау һәм башкалар. Бу очракта мәгънә бераз үзгәрә. Кияүгә, киленгә, яшь парларга карата үгет-нәсихәт әлеге фольклор берәмлегенең төп эчтәлегенә әверелә. Әлбәттә, бу ике юнәлешне бер-берсенә каршы куярга да кирәк түгелдер, чөнки шул ук кияү, килен, яшьләр темасына багышланган җырларда да әфсенләү, сихерләү (мәҗүси теләк) поэтикасы, җыр аһәңе кулланылырга мөмкин. Элегрәк туй җырларында сихри йола традицияләре көчлерәк булгандыр, мифлар катламы да күбрәк кергәндер, кулланылгандыр, дип уйларга ныклы нигез бар. Шулай ук миф белән бәйле әфсен текстларын да көйләп әйтү, җырлап уку гадәте бар лабаса.

Арбау моменты, шул ук вакытта, башка фольклор жанрларына, мифологик-магик ышануларга, ырымнарга төшеп калган. Халыкта, мәсәлән, «Арбавын белсәң, кара елан да карышмый» дигән халык мәкале бар. Монда да сихернең, магиянең тәэсир итү көче, сихерләү моменты алгы планга чыга. Димәк, арбауларда да ниндидер сихри моментка ышану, миф тудыру төп шарт булып тора.

Арбау дигәндә, берничә шартны ачыклап, билгеләп кую кирәктер. Чынлыкта арбау текстлары сихер, теләк, җыр-такмак, йола традицияләрен үзенә җыйган. Еш кына келәү, әфсен, арбау, тулгау, юрау, тыю жанрларының сыйфат-үзенчәлекләре барысы бергә укмашып килә. Ләкин арбау башкаларыннан психологик моментның көчлерәк булуы белән аерылып тора. Кемнең дә булса игътибарын үзенә җәлеп иттерү, карату, сихри сүз (теләк) белән үз ихтыярыңа буйсындыру хакында сүз бара. Борынгы мифлардан кергән сюжетлар, образ-персонажлар да мәҗүси ышануларга нигезләнеп сайлана. Мәсәлән, «Яңа өйне арбау» текстында шундый юллар бар: «Чулпан бабай мал бирсен, Зәнки бабай юл бирсен!» Бу очракта, теләктән тамырланган тәэсир итү, күндерү, үгетләү, өметләндерү поэтикасы кулланылган. Алдарак әйткәнебезчә, бу поэтика бигрәк тә туй җырлары белән бәйле, ул күбрәк үгет-нәсихәткә корылган арбау текстларында очрый.

Бер сүз белән әйткәндә, кеше яшәеше-тормышы белән бәйле арбау ул – җыр-такмак интонациясе белән әйтелә торган сихри теләк. Изге теләк теләү, илаһи мөнәсәбәт белдерү, яхшылык, иминлек, бәрәкәт, бәхет юрау, һәм бу теләкнең, юрамышның имин, сәламәт, бәхетле язмышка якынайтачагына ышандыру – бу жанрның төп эчтәлеге. Зарур эчтәлеге.

Әлбәттә инде, зарурлык булган җирдә тыю да булырга тиеш. Арбау текстларында (йоласында) нәрсә ярамый, нәрсә рөхсәт ителми соң? Арбау текстларында өч нәрсә – мәҗбүр итү, дучар итү һәм хөкем итү катгый тыела. Бәлки, дүртенчесен дә өстәргә кирәктер: арбауларда рәнҗеш-каргау рөхсәт ителми. Кеше теләгеннән башка, көчләп арбау йоласын башкару, теләк теләү, шуның белән ышандыру, тәэсир итү, димәк ки, кешенең үз ихтыярыннан башка рухын, асыл характер сыйфатларын үзгәртергә тырышу – элек-электән зур гөнаһ булып исәпләнгән.

Махсус арбаучылар булган. Чөнки, бер үк функцияне башкарсалар да, арбау гадәти әфсеннән нык кына аерыла. Ул үзе бер кагыйдәләр системасын, әхлак кодексын тәшкил итә. Әйтүебезчә, аның шартлары, таләпләре бар. Арбауда ялгышырга ярамый, текстны да, аһәңне дә дөрес сайлау зарур. Кеше күңеленә ялгыш, саксыз тәэсир итсәң, бу кешенең гомере буе кимсенгән һәм кимсетелгән, рухи зәгыйфь бәндә булып калуы бар. Хәзер инде аңлашыладыр: арбаулар – үзләренең психологик шаукымнары белән, борынгыдан килгән әхлакый тәгълиматны һәм мифологик (мәҗүси) образлылыкны куллану, аңа нигезләнеп, күңелгә, җанга тәэсир итү, яшәешкә, язмышка йогынты ясау мөмкинлекләре белән мәҗүси догаларга тиң жанр.

Табигать арбаулары белән хәл башкачарак тора. Әлбәттә, бу очракта да текстларда тәэсир итү көче беренче планга чыга, әмма табигать күренешләре һәм образлары белән аралашканда ул компромисс юлы белән хәл ителә. Алда кара елан хакында арбау әфсене телгә алынды. Елан ничек кенә яман персонаж буларак каралса да, аның белән мөнәсәбәтләр компромисска, ягъни, үзара аңлашуга нигезләнгән була.

## ТУЙ ЙОЛАСЫ БЕЛӘН БӘЙЛЕ АРБАУЛАР

### Димчеләрнең арбау сүзләре

Бу арбау сүзләреннән соң кызның ата-анасы шунда ук «эреп» төшәләр һәм кызларын кияүгә бирергә риза булалар, имеш:

Ефәк баулы былбыл кош
Бардыр синең иләңдә,
Каеш баулы лачын кош
Бардыр минем иләмдә.
Өер-өер айгырдан
Җайдак булып килгәнмен,
Чаптар атым чаптырып,
Чыңлап сиңа килгәнмен.
Бохараданияр алган мин,
Юлым сиңа ярган мин,
Каеш баулы лачыным бар,
Былбылыңа килгән мин;
Тимер булсаң, мин күмер,
Эретергә килгән мин.

### Килен каршылау

Килен каршылау арбаулары, мәсәлән, егетнең әнисе, апалары, җиңгиләре тарафыннан әйтелә (бу арбаулар авызландыру җырлары, авызландыру алкышлары дип тә әйтәләр). Егетнең әнисе, киленгә бал-май каптырганда болай ди:

Атаң-анаң йоласы,
Пәйгамбәрләр догасы,
Май кебек йомшак күңелле бул,
Бал кебек татлы телле бул,
Тату торыгыз!
Аны апалары, җиңгиләре куәтләп ала:
Ак юллы бул,
Ак күңелле бул,
Аягың җиңел булсын!
Авызың аш белән килсен,
Аягың белән ырыс килсен!
(Ырыс: борынгы төрки телдә – бәхет)



## Килен китмәсен дип арбау

Танылган фольклорчы Илбарис Надиров фикеренчә, туй арбауларының вазифасы – киленне магик теләкләр әйтеп каршылау, аның кияү һәм каенана йортындагы киләчәк тормышын сүз-йола кодрәте ярдәмендә ипле һәм мул итү. Вакытлар үтү белән алар халыкның гаилә тормышына һәм килен кешенең вазифа-бурычларына бәйләнешле теләкләрен гәүдәләндерүче киңәйтелгән келәү рәвешен алганнар һәм каенана яки кияүнең апасы-җиңгәсе, йә булмаса бу йоланы яхшы белгән өлкән яшьтәге хатын-кыз тарафыннан әйтелгәннәр.

* * *

Исән генә килдеңме, балам,
Ак күңелдән сиңа арбау салам:
Төпле аягың белән, талмас кулың,
Таймас табаның белән кил!
Юраганың юш булсын,
Курыкканың буш булсын,
Янгышагың юл булсын,
(Янгышак – өйдә күз-колак булып торучы)
Эшең, көнең уң булсын,
Ашың, суың мул булсын;
Йөзең – Айдай, сүзең – балдай,
Күңелең майдай булсын.
Арысландай алты батырың,
Җиләктәй җиде матурың тусын;
Батырларың мал тапсын,
Матурларың яр тапсын, –
Алтының алтындай игелеген,
Җиденең җефәктәй изгелеген күреп картай!

* * *

Казаның өреле булсын,
Китмәскә килерең булсын,
Чүмергәнең май булсын,
Ашаганың бал булсын!
Гаиләң ишле, бай булсын,
Абзарың тулы мал булсын,
Күңелең кинә тотмасын,



Д. Нәүрүзова рәсеме

Авызың серкә йотмасын;
Сыер-танаң мөңгердәп,
Кош-кортларың көңгердәп
Күз ачтырсын, киленем,
Көн ачтырсын, киленем;
Өлгерем бул, киленем, –
Арбавым шушы минем.

## Өйләнешкән яшьләрнең бәхетен арбау

Кыңгыраулар чаң кага,
Урамнарда шаң кала;
Ике яшьнең бәхетенә
Бөтен дөнья таң кала.
Атларыбыз, атларыбыз,
Канатлы чаптарыбыз;
Безнең дә бер булыр икән
Киленле чакларыбыз.
Әй, Ай батсын, Ай батсын,
Кызарып таңнар атсын.
Тулган Айдай яшь киленне
Туганнарыгыз яратсын!

## Кодаларга әйтелә торган арбау

Синең генә, кода, атларың,
Алдан җибәр җирән чаптарың;
Бәхетең бар, кода, дәүләтең бар,
Рәхәт кенә яшәр чакларың.
Кызыл гына төлке – кырлар күрке,
Камчат та гына бүрек – ир күрке;
Камчат та гына бүрек – ирләр күрке,
Сез кодакайлар – түр күрке.
Каргалыкай буе түтәл-түтәл,
Түтәленнән былбыл кош үтәр;
Бу дөньялар бездән үтәр китәр,
Тату яшәүләргә ни җитәр?!
Кикрикүк әтәч – күк әтәч,
Атлап барыйк үрне менгәнче,
Ташлашмаек гүргә кергәнче;
Атлый-йөгерә килә күк юрга,
Хәерле гомер бирсен күп елга!

# САУЛЫК-СӘЛАМӘТЛЕК, ИМИНЛЕК ТЕЛӘП ӘЙТЕЛӘ ТОРГАН АРБАУЛАР

## Кеше үз-үзенә саулык теләп әйтә торган арбау

Кеше үзенә иминлек, сихәтлек-сәламәтлек теләгәндә шушы арбау текстын әйтергә тиеш (аның бер кыйпылчыгы әфсен рәвешендә сакланып калган):

Кояшым сүнмәсен,
Суларым кипмәсен,
Тауларым нык булсын,
Йөзләрем ак булсын,
Күңелем пакь булсын!

Бу әфсеннең борынгы арбау мәгънәсе шундый: кояш – күзләр, сулар – кан, таулар – сөякләр; шундыйрак мәгънәдәге магик әйтемне борынгы Орхон-Енисей чөй язуларында да очратабыз: «Синең кан су кебек акты, синең сөякләр таулар кебек ятты...»

Әлеге арбау текстын башкаларга карата да кулланырга мөмкин.

## Үзеңә судан сихәтлек, шифа теләп әйтелә торган арбау

Шулай ук өзек-кыйпылчык буларак кына сакланып калган, телдә әфсен рәвешендә йөри. Беренче очракта – арыган чакта, икенче очракта авырган чакта әйтелә:

Арулыгым, пакьлегем,
Исәнлегем, саулыгым,
Тән керемне суга салдым,
Үзем судан пакь калдым...

* * *

Авыруым, авыруым,
Авызым тулы даруым.
Арулыгым, пакьлегем,
Исәнлегем, саулыгым,
Тән керемне суга салдым,
Үзем судан пакь калдым...

Бу арбаулар башкаларны сихәтләндергәндә дә әйтелергә мөмкин.

## Яңа туган баланы авызландыру арбавы

Кендек әби баланы авызландыра, авызына (иреннәренә) бал, май тидерә дә түбәндәге арбау текстын пышылдый:

Пар канатлы булсын,
Алтын канатлы булсын,
Ата-инәле, бәхетле-тәүфыйклы,
Тәмле телле булсын!
Бәхетле-тәүфыйклы булсын,
Алтын канатлы булсын!

## Баланы мунчада юындырганда әйтелә торган арбаулар

Атаң кискән утын түгел,
Анаң яккан мунча түгел,
Аюдай ага бул,
Бүредәй бога бул,
Аю баласы, бүре баласы,
Мунча ташы, бүрәнә башы.
Картны күрсәң, «бабай» диген!
Карчыкны күрсәң, «әби» диген,
Яшьне күрсәң, «абзый» диген,
«Җиңги» диген!
Тәмле-татлы телле бул!
Атаң ташы түгел –
Мунча ташы!
Минем кулым түгел,
Әйшә-Батманның кулы!
Минем телем түгел –
Идел кичкән инәкәләр теле!
Кәбестәгә су салдым,
Суы сарыксын!
Ят та йокла, тор да уйна!

* * *

Аю баласын чабам,
Бүре баласын чабам,
Бәхетле бул,
Тәүфыйклы бул,
Ата-анаңа ихтирамлы бул,
Тәмле телле бул,
Алтын канатлы бул,
Анаңны ана ит,
Атаңны ата ит,
Әбине «әби» диң,
Бабаңны «бабай» диң...

* * *

Кәбестәгә су салдым,
Суы сарыксын,
Үзе калыксын,
Имәндәй таза булсын,
Үзәктәй озын булсын.
Ябалактан йон ал,
Бүдәнәдән – май,
Кәбестәдән – аклык,
Судан – пакьлек;
Баламнан килер дөньяга шатлык.

## Баланы үс-үс иттергәндә әйтелә

(Бу арбау әфсене шулай ук баланы коендырганда да әйтелә)

Үс, үс, үс итә,
Балам үсеп тә житә.
Булчыл, булчыл, булчыл бул,
Бүдәнәдәй тулчыл бул!
Үр куяныдай күзле бул,
Адәм тапмас сүзле бул!
Минем кулым түгел,
Әйшә-Батман кулы.

Коенганың Идел суы,
Йөрер юлың – атаң юлы,
Торыр жирең – бабаң жире,
Сайрар телең – анаң теле,
Карышма да тибешмә,
Яңа керден инешкә,
Киерелгәндә киртә буе,
Сузылганда солы буе,
Үс, үс, үс!

* * *

Үс, үс, үс итә,
Балам үсеп тә житә,
Аюдай олпат бул,
Бүредәй батыр бул,
Арыслондай егәрле,
Болондай матур бул!
Төлкедәй зирәк бул,
Һәркемгә кирәк бул!
Жыландай жылгыр бул,
Куяндай күзле бул!
Һәрвакыт бер сүзле бул!
Сандугачтай телле бул,
Сагынырдай илле бул!
Үс, үс, зу-у-ур булып үс!

## Елаган баланы тынычландыру

Елама, бала, елама,
Йокың килгән, улама,
Атаң кайтыр, куй суяр,
Бер ботын сиңа куяр.
Бабаң кайтыр – бал бирер,
Анаң кайтыр – май бирер,
Агаң кайтыр – тай бирер,
Шул тайларга менәрсең,
Куй имчәген имәрсең...
Елама, балам, елама!..

* * *

Әллем, әллем, әл бәби,
Ал бишектә ят, бәби,
Атаң кайтыр – бал бирер,
Анаң кайтыр – май бирер,
Ул майларга туярсың,
Жылавыңны куярсың...

Искәрмә: баланы тынычландыру, «үчтеки» иттерү, аны уйнату, юындыру, ашату, дәвалау, йоклату белән бәйле текстларның күпчелеген, шулай ук «бишек жырлары»н да арбаулар рәтендә карарга мөмкин.

# Тәтеш төбәгендә халык бәйрәмнәре

**Эльмира Сәлахова,**
*тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре*

**Татар халкы үзенең гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары белән бай халык. Алар гасырлар дәвамында буыннан-буынга сакланып килгән. Әлеге язмабыз Казан губернасының Тәтеш өязенә караган авыллардагы бәйрәмнәр һәм алардагы халык уеннары турында. Элеккеге Тәтеш өязенә хәзерге Тәтеш, Апас, Кама Тамагы районнары һәм Буа районының бер өлеше кергән.**



Татар халкының иң зур бәйрәмнәреннән, Җыен белән Сабан туен атарга мөмкин. Инкыйлабка кадәр халыкның иң яраткан бәйрәме – Сабан туеннан да бигрәк, Җыен булган. Җыенны берничә авыл берләшеп уздырган.

Икенче бәйрәм – ул, әлбәттә, Сабан туе. Аларның кайсысы беренчел, ә кайсысы икенчел дигән сорауга җавап бирү дә мөмкин түгел, чөнки халык аларны төрле вакытта уздырган һәм икесенең дә үз функцияләре булган. Халык тарафыннан алар бертөрле кабул ителгән, әмма Җыен бүгенге көндә татар халкы тормышыннан төшеп калган, ә Сабан туе үзенең беренчел эчтәлегеннән шактый ераклашса да, яшәвен дәвам итә, хәзер дә бәйрәм ителә.

Тарихчы Гайнетдин Әхмәрев фикере буенча, Сабан туе бәйрәме игенчелек белән шөгыльләнгән, озак гасырлар утрак тормышта гомер иткән халыклар яшәгән төбәкләрдә үткәрелгән. Күчмәчелек чорында Сабан туе түгел, ә Җыен бәйрәме бик популяр булган. Тарихчы хәтта эчтәлегендә, аларда уйнала торган уеннар арасында да аерма барлыгын күрсәтә. Тәтеш төбәге татарлары, әлбәттә, Сабан туен бәйрәм иткәннәр, әмма биредә Җыен бәйрәменең дә чагылышы бар.

## ҖЫЕН

Тарихчы Г. Әхмәрев үзенең туган төбәге Тау ягында – Яшел Үзән районына караган авылларның Җыен бәйрәмнәре хакында тасвирлы мәгълүмат бирә[1]. Ә Тәтеш өязендәге Җыеннар турында халык хәтерендә сакланганнардан һәм галимнәрнең хезмәтләре аша күзалларга мөмкин. Шундый зур Җыеннарның берсе «Кушкапка» дип аталган. Халык хәтеренә караганда, Кушкапка Апас төбәгенең бик борынгы бәйрәме булып саналган. Уздырылу вакытын халык табигать күренешләре аша билгеләгән, ягъни игеннәр өлгергәч, арышлар серкә очырган вакытта бәйрәм ителгән. Ул Апас районына караган Югары, Түбән, Урта Балтай, Олы, Кече Бакырчы, Кара Борнаш, Чиру-Бураш, Каратун, Колчык, Көлкәш, Чирмешән, Чәтбаш, Шәмәк, Күкшем, Тутай, Аксу, Дәүләки, Багыш, Ябалак, Кызыл Тау (Коллар), Морзалар кебек 28 авылны үз эченә алган. Аның үзәге булып Түбән Балтай авылы саналган, үзе Урта Балтай белән Түбән Балтай авыллары арасындагы җирлектә уздырылган[2].

«Кушкапкага яңгыр төшмәсә, халыкның иңе төшә» дигән әйтем дә булган. Ул, бигрәк тә, бала-чаганың көтеп алган бәйрәменә әйләнгән. «Утыртып бәйрәмгә алып барсыннан өчен, бала-чага атларга печән җыя иде», дип искә ала җирле халык[3]. Читкә китеп эшләүчеләр дә туган якларына шушы бәйрәмне туры китереп кайтырга тырышканнар.

Алданрак яшьләр өчен аерым уеннар оештырылган, ул «Кече Кушкапка» дип аталган. Бәйрәмгә төрле вак-төяк сатучылар, кәмит («кәмит» дип бу якларда карусельне атыйлар) килгән. Мондый кәмиткә халык акчасын алдан ук әзерләп куйган, җыеп барган. Бәйрәм башында Кушкапка Җыены урынын җигүле, кыңгыраулы атларга утырып әйләнеп чыгу гадәте дә булган. Кызыл Тау (Коллар) авылы кешеләре хәтерендә калганнар буенча, Кушкапка Җыены вакытында авыл башындагы болынга төшеп уеннар уйнаганнар, биегәннәр. Болынга төшү дә «куш капка», ягъни парлы капка рәвешендә барган, Җыен исеме дә шуннан алынган булырга тиеш. Кушкапка бәйрәмен Түбән Балтай авылы кешеләре дә хәтерли. Бу Җыеннарда халык уеннары уйналган. Идрәз-Тенки (Апас районы) авылында галимнәр тарафыннан «Зәлидә» уенындагы җырдан өзек язып алынган. Бу уенны «Наза» уены дип тә атаганнар.

*Сандугачым син икәнсең,*
*Күрмәдем килгәнеңне.*

[1] Салахова Э.К. Татарские народные праздники и традиции глазами историка // Историческая этнология. – 2019. – Т. 4. – № 1. – С. 151-160.
[2] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 191.
[3] Шунда ук. – Б. 192.

*Тулган айга ошатам*
*Җылмаеп көлгәнеңне.*
*Ал бирәм алучыга,*
*Гөл бирәм алучыга.*
*Ал тирәле җаулык бирәм*
*Озата баручыга*[4].

Җыенда уйнала торган «Тоттырма» уенында яшьләр парлашып тезелеп баскан, парсыз берәү көтүче булган. Уен башлангач, парлар бер-берсеннән аерылып китеп йөгергәннәр, көтүче аларның берсен тотарга тырышкан. Парсыз калганы көтүчегә әйләнгән. Яшь кызлар яулыклар белән «Сукыр лампа», «Йөзек салыш» «Патша сикерү», «Чиша тәгәрәтү» кебек уеннар да уйнаганнар. (Чиша – Тау ягы сөйләшендә «шешә» дигән сүзне аңлата). Шешәне әйләндереп җибәргәч, авыз ягы кемгә карый, шул уенчы йә җырлаган, йә биегән.

«Патша сикерү» – җиргә сызылган шакмаклар буенча сикереп уйнау. Сызыкка аяк белән тию җиңелү саналган.

«Аламын кош, бирәмен кош» дигәне – сату-алу уены.

5 кечкенә чуерташ белән уйнала торган «Чуерташ» – балаларның да, яшьләрнең дә яраткан өстәл уены.

«Ызба-ызба» да балаларның яратып уйный торган уеннары булган, ягъни чыбык-чабык, ватык чынаяк кисәкләре җыеп, шулардан өй ясап уйнаганнар. Тау ягында өйне «ызба» дип атаганнар.

Июнь башында Бәбки, Колгана, Дәвеш, Каенлык (Апас, Буа районнары) авыллары яшьләре җырлы-биюле һәм уеннар уйнала торган Каравыл тавы Җыены уздырган.

«КУШКАПКАГА ЯҢГЫР ТӨШМӘСӘ, ХАЛЫКНЫҢ ИҢЕ ТӨШӘ» ДИГӘН ӘЙТЕМ ДӘ БУЛГАН. УЛ, БИГРӘК ТӘ, БАЛА-ЧАГАНЫҢ КӨТЕП АЛГАН БӘЙРӘМЕНӘ ӘЙЛӘНГӘН. «УТЫРТЫП БӘЙРӘМГӘ АЛЫП БАРСЫННАН ӨЧЕН, БАЛА-ЧАГА АТЛАРГА ПЕЧӘН ҖЫЯ ИДЕ», ДИП ИСКӘ АЛА ҖИРЛЕ ХАЛЫК.



[4] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 145-147.



Үзәге Килдураз авылы (Буа районы) булган авыллар бәйрәме «Кәлти» дип аталган. Кәлти Җыенында Килдураз, Колгына, Кабалан, Өчмунча, Үгез Куагы (Буа районы) авыллары катнашкан. Җомга көнне Килдураз авылы янында ат чабышлары узган, аннан зур Җыен ярминкәсе үткәрелгән. Аны 15 майдан башлап уздырганнар[5].

Тәтеш өязенең Каенлык авылында (Буа районы) үтә дә үзенчәлекле «Майуны» бәйрәме булган. Шифалы үләннәр чыккач, табигатьнең җанлануына багышлап уздырыла торган әлеге бәйрәм бүгенге көндә дә сакланып калган. Кунаклар җыелгач, бергәләп, урманга барып шифалы үләннәр җыйганнар, аннан күңел ачканнар. Май аеның 10нчы числоларында уздырылганга исеме дә шулай аталган. Тирә-яктагы башка авылларда мондый бәйрәм-йоланың булуы күзәтелми, ул бары тик Каенлыкның гына уникаль бәйрәме. Гомумән, тирә-якта игенчелек белән көн күргән татарларның урман тормышына әллә ни игътибары булмаганны исәпкә алсак, бу ниндидер тәэсир нәтиҗәсендә, яисә авыл халкының үзенчәлекле тарихы булуы хакында фикерләргә урын калдыра. Галимнәр күзәтүе буенча, моңа охшаган Юа Җыены Ык буе бассейнында яшәгән халыкларда күзәтелә.

Апас районының Кара Борнаш, Дәвеш, Кошта авылларында Кече Җуа һәм Олы Җуа, яисә «Җуалык» дигән бәйрәм уздырылган, әмма ул дару үләннәре җыю белән бәйле түгел, уздыру вакыты 20-22 май көннәрендә булган. Бу бәйрәмдә бер-берсенә кунакка йөргәннәр, үзләре кунак иткәннәр[6].

Җыен кысаларында, авылларда бергәләп уеннар, ярышлар уздыру гадәте дә булган. Шундыйлардан, елга бер мәртәбә – 19 майда Олы болын уен-ярышлары үткән. Монда Шәмәк һәм Коллар авыллары (Апас районы), Тәтеш өязенең хәзерге Кама Тамагына кергән Олы Салтык, Олы Яңасала, Даныш, Олы Кариле авыллары яшьләре бергәләп, Сулып Җыены уздырганнар. Ул бер көнлек уеннар рәвешендә, 1 июньнән башлап, уздырыла торган булган. Бу уеннарны «Сирәм» (чирәм) дип тә атаганнар, чөнки аны яшь йомшак чирәм чыккач үткәргәннәр[7]. Мондый күмәк бәйрәмнәр халыкның бер-берсе

[5] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 167.
[6] Шунда ук. – Б. 167.
[7] Шунда ук. – Б. 90.

белән аралашуына, кунакка йөрешүенә, яшьләрнең танышуына, туганлашуга китергән. Метрика язмаларындагы никахларга игътибар итсәк, нигездә алар шушы Җыен кысаларында аралашкан авыл кешеләре арасында булган.

Чабыр Җыены хәзерге Кама Тамагы районына кергән Бәки, Олы, Кече Кариле, Чаллы, Келәнче, Олы һәм Кече Болгаер (Апас районы) авылларында узган. Ул 18 июньнән башлап, Христофоровка дигән алпавыт утарында үткән. Шул көннәрдә бираедә ярминкә дә эшләгән.

Хәзерге Апас районына кергән Энәле, Карабай, Иске Җөмралы авыллары, 20-25 май көннәреннән башлап, Шыкма Җыенына җыела торган булганнар. Ә июнь башында, хәзерге вакытта район үзәге булган Апас авылының үзендә Көлсит бәйрәме уздырылган. Чиру-Бураш авылында (Апас районы) Тау уен Җыены, яисә Биек Тау уеннар бәйрәме үткән, аның кайчан уздырылуы хакында төгәл мәгълүмат сакланмаган. Татар авылларының бәйрәмнәре кайвакытта зур базарлы рус авыллары бәйрәмнәре белән, еш кына зур ярминкәләр вакытына туры китереп оештырылган. Халык бер үк вакытта сату-алу эшен дә башкарган, ял да иткән. Рус Ындырчысы авылындагы ярминкә барган көннәрдә, июнь ахырында, Югары Ындырчы, Шәмбалыкчы, Болын Балыкчы, Кормаш, Үтәмеш, Түбән Биябаш (Апас районы) авылы кешеләре Кызыл Яр (Җар) Җыенына җыелганнар.

Тау ягы мәлки керәшеннәренең дә үз Җыены, уеннары булган. Алар чиркәү бәйрәмнәре белән бәйләп үткәрелгән. Мисал өчен Троица вакытында Семык бәйрәме узган, Питрау көндә соңгы йомгаклау уеннарын үткәргәннәр. Аларга күрше чуаш авылы яшьләре дә кушылган[8]. Бу бәйрәм Семык исемендә мариларда да бар, алар аны җәй башлану бәйрәме буларак үткәрәләр.

Пасха узып 7 атна үткәннән соң, куаклар чәчәк ата башлаган вакытта, Чуаш Ковалында үткәрелгән ярминкәгә татарлар да бик теләп кушылганнар. Бакырчы, Сүнчәләй, Акъегет, Олы Кошман, Иске Чәчкап, Олы Кайбыч, Җабалак, Татар Исламы (Яшел Үзән районы) авылы татарлары бу Җыенны «Семык» (Чимек) дип татарчалаштырып атап йөрткәннәр. Чимек Апас районына караган Балтай авылында да үткән, 3-4 көн дәвамында барган. Тарихчы Г. Әхмәрев тә Семыкның татарлар арасында бәйрәм ителүен, халыкның бу бәйрәмгә яратып йөрүен яза. Ул аны татарларга христиан динен тотучы халыклар белән тыгыз элемтәдә, дустанә мөнәсәбәттә, күршедә яшәү нәтиҗәсендә кергән, һәм аерым бер дин белән бәйле күренеш түгел, ә Җыенның бер формасы, бер чагылышы итеп саный[9].

Тау ягының хәзерге Яшел Үзән һәм Кайбыч районнарына караган өлеше Тәтеш өязенә кермәсә дә, ул җирләрдә булган Җыеннарны да әйтеп үтәргә кирәк, чөнки халык тормышы рәсми административ-территориаль бүленеш белән чикләнми. Тәтеш өязе татарлары Зөя, Чуел өязе авылларындагы туганнары, якыннары белән аралашып яшәгән, аларга кунакка йөргән. Шулай ук Г. Әхмәрев тасвирлап калдырган «Таган асты», «Кала ала уен» бәйрәмнәре Күгәй Әрә, Айдар Тау иле, Мамадыш, Карашәм, Татар Наратлысы авыллары яшьләренең уеннары белән бергә узган. «Таган асты» бәйрәмендә таган атыну (карусель) иң матур мизгел саналган. Норлат, Мулла иле, Бузый авылларының Тикен бәйрәме христианнарның «День Тихвинской Божьей Матери»га туры китереп эшләнгән. «Тикен» дигән исеме шуннан татарчалаштырып бирелгән. Бу бәйрәм 22 июньгә туры килгән, ә

[8] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 91.
[9] Әхмәрев Г. Болгар тарихы. – Казан: Бәянелхак, 1909. – 128 б.



АПАС РАЙОНЫНЫҢ КАРА БОРНАШ, ДӘВЕШ, КОШТА АВЫЛЛАРЫНДА КЕЧЕ ҖУА ҺӘМ ОЛЫ ҖУА, ЯИСӘ «ҖУАЛЫК» ДИГӘН БӘЙРӘМ УЗДЫРЫЛГАН. БУ БӘЙРӘМДӘ БЕР-БЕРСЕНӘ КУНАККА ЙӨРГӘННӘР, ҮЗЛӘРЕ КУНАК ИТКӘННӘР. ҖЫЕН КЫСАЛАРЫНДА, АВЫЛЛАРДА БЕРГӘЛӘП УЕННАР, ЯРЫШЛАР УЗДЫРУ ГАДӘТЕ ДӘ БУЛГАН.

23 июнь көнне Утяшка авылында ярминкә узган. Тикен соңгы Җыен булып үткәрелгән, аннан урак эшләре башланган, бәйрәм итәргә вакыт калмаган. Шуңа да «Тикен җитте – эш җитте», дигән гыйбарә бар[10].

## САБАН ТУЕ

Җыен бәйрәмнәре инкыйлабка кадәрге чорда гөрләп торса да, зур этрафны биләсә дә, совет чорында бу бәйрәм югала, татар авылларының болай берләшеп, зурлап җыелып аралашуы хупланмый, ул Совет власте өчен кирәкмәгән гамәл була. Сабан туе бәйрәмнәренең бу яктан язмышлары бәхетлерәк, аларның гомере озынрак. Тау ягында, аерым алганда Тәтеш төбәгендәге Сабантуйлар, аерым бәйрәм генә түгел, ә ярминкәле, уенлы-ярышлы тулы бер комплекслы чара була. Болын-Балыкчы авылы кешеләре хәтере буенча, Кызыл яр дигән урында ат чабышы да, көрәше дә, кәмите дә һәм ярминкәсе булган Сабан туе уздырганнар. Зөя буенда сарык чалганнар, хәтта халык сөйләве буенча, бу вакыйгага сыра да әзерләгәннәр. Күп кунак чакырылган. Тарихчы Г. Әхмәрев «Тәтеш өязенең Күл-Черкене карьясендә (авылында) быелгы Сабан туенда 117 чирек аракы эчеп бетергәннәр, имеш», дип язган газетадагы хәбәргә җавап итеп, Сабан туе турында махсус аңлатма мәкаләсе яза. Әйе, кызганыч, андый

[10] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 166-167.



**Иске Әтрәч авылы, Тәтеш районы**

хәлләр дә булуы, ихтимал, әмма аерым очракларны күпертеп, Болгар чорыннан ук килгән, татарларның кадерле бәйрәмнәренә тап төшерү дөрес булмас иде, бәлки болай таплау махсус та эшләнүе мөмкин дигән фикерен белдерә[11].

Сабан туе – ул кунаклар чакырыла торган бәйрәм, туган-тумача, нәселдәшләр бергә җыелып аралаша торган, бәйрәм итә торган чара. Мисал өчен, Багыш авылында Сабан туе чәчүгә кадәр үк үткәрелгән, зур эш башланганчы, бәйрәм ясап, көч туплап куйганнар, ә инде эшне төгәлләгәч, Кушкапка Җыены вакыты җиткән. Дәүләки авылында Сабан туе июньдә, чәчү беткәч оештырылган. Һәр авылның үзенә җайлы үткәрү вакыты булган, аның датасына табигать шартлары да тәэсир иткән. Апас районы Багыш авылы кешеләренең хәтерләре буенча, Сабан туена кабартмалар, җуачалар (бавырсак) пешергәннәр, бәлеш салганнар, токмач кискәннәр. Каклаган казны Сабан туе өчен саклап торганнар. Җыен уеннарында күбрәк яшьләр катнашса, Сабан туе ул олыларны да берләштергән бәйрәм була. Яшьләр матур киемнәрен киеп күңел ачсалар, олы буын бу уеннарны карарга килгән.

Бәйрәмнәргә бүләк җыюда да һәрбер төбәкнең үз үзенчәлеге булган. Мисал өчен, Сабан туена, яисә карга боткасына йомырканы, бүләкне кайбер өлкәләрдә җәяү, кайберләрендә ат белән җыйганнар. Ат белән җыю күбрәк Уржум, Уфа якларында булса, ә җир эше белән көн күрүче игенчеләр яшәгән якларда җәяүләп йөргәннәр. Тәтеш өязендә бүләкне яшүсмерләр җәяүләп, Апас районына караган Тутай авылында Сабан туена бүләкне җигелгән атларны бизәп, гармун уйнап, җырлап, биеп җыйганнар. Сабан туеның төп бүләге яулык, йомырка булган. Сабан туе – ул яшь киленнең уңганлыгын да күрсәтә торган урын, һәр килен үзе чиккән сөлгене бүләк итеп тапшырырга тырышкан. Шул ук районның Болын-Балыкчы авылында гармуннар уйнап, бүләкне колгага бәйләп, җәяү генә җыйганнар. Чәчүгә чыкканчы, Сабан туе бәйрәме кысаларында, Урта Балтай, Кече Балтай (Апас районы) халкы атлар чабыштырган. Көчләрен сынау максатыннан, яхшы атларны авыл янындагы Каравыл тавына чаптырып менгәннәр. Дәвештә Кыз тавына менә торган булганнар[12].

---

[11] Әхмәрев Г. Сабан туе // Казан мөхбире. – 1906. – 7 май.
[12] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 190.

## ХАЛЫК УЕННАРЫ

«Зәлидә» уенына аерым игътибар итәсе килә, чөнки ул инкыйлабка кадәр татарларның җырлы-биюле уеннарында төп урынны алып торган, Зәлидә хәзерге хореографиядә дә тарихи күренеш буларак яктыртылып килә. Тау ягында Зәлидәне Сабан туенда да, ташу киткәндә дә, кичке уеннар вакытында да уйнаганнар. Мисал өчен, Дәвеш авылында Кыз тавына менеп, корырак җирне сайлап, Зәлидә уены өчен әзерли торган булганнар. Уенның тәртибе болай булган: уртада торган кешегә тирә-яктагылар җыр җырлаган, аннары шул кеше биеп әйләнгән, кем янына килеп басса – шул уртада калган. Шул ук уеннар кысасында «куышлы уен» уйнаганнар. Ул үзенә күрә, күңел ачуга да, шул ук вакытта яр сайлауга да ярдәм иткән. «Тоттырма чабу» уенында егетләр куышлы уйнаганда үзләренә ошаган кызны пар итеп сайлаганнар[13].

Тәтеш өязенең Черкен авылында (Буа районы) үзенчәлекле йола була: ишек алдыннан чыкканда атның башына он сибәләр, ипи каптыралар. Бу «Атлар хакына да икмәк булсын», дигән ышану белән эшләнә. Уңыш әйбәт булсын дип, я муллага, я ярлырак кешегә сәдака итеп оннан, яисә йомыркадан ясалган ризыклар да илткәннәр[14]. Керәшен татарларында йомырка белән ипи кисәген буразнага күмеп кую йоласы булган. Тәтеш өязе Иске Корбаш авылы (мәлки) керәшеннәре чәчү алдыннан сыер корбан иткәннәр. XIX гасырның 60нчы елларында уңыш булсын, дигән теләк белән хәтта ат чалганнар. Бу йоланы алар «сабан корманы» (корбаны) дип атаганнар. Корбаннарны, еш кына зиратларда, бигрәк тә иске зиратларда, ә Тәтеш өязенә кергән Олы Кариледә (Кама Тамагы районы) арыш басуында чалганнар.

Җәй көне үткәрелгән яңгыр теләү, яңгыр чакыру йоласы, нигездә, керәшен татарларында очраса да, сирәгрәк кенә булса да, Тәтеш өязе татарларында да күзәтелгән. Ул йола «яңгыр келәве, яисә, яңгыр теләү» дип аталган[15]. Мисал өчен, татарлар гомер итә торган Черкен авылында (Буа районы) бу йола үтәлгән[16], аның бүгенге көндә дә үткәрелүен Килдураз волостена кергән авылларда күзәтергә мөмкин. Теләүләр белән булган бу гадәтләрдә мәҗүсилек чалымнары бар, әмма халык аларны үзләренең борынгы гадәтләре итеп кабул иткән, муллалар да моңа әлләни каршылык күрсәтмәгән. Мисал өчен, Кече Карамалы авылында (Кама Тамагы районы) бүгенге көндә дә «Келәү куагы» дигән урын бар. Ел саен «Шилек» дигән йола үткәрәләр, корбан итеп тавык суялар, теләкләр теләләр.

Халык бәйрәмсез яшәмәгән, бәйрәм ул халык тарафыннан тудырылган һәм гасырлар дәвамында формалашып, камилләшеп килгән тарихи үткәненең чагылышы. Бәйрәм язма чыганак түгел, халык яшәткәндә – яши, кулланылмый икән – югала. Шуңа да күп кенә бәйрәмнәр хакында хәбәрләр инде югалган. Биредә тасвирланганнары язма чыганакларда, яисә халык күңелендә сакланып калганнары гына. Халык бәйрәмнәре җирле халыкның менталитетын аңларга, аларның борынгы тарихи үзенчәлеген күзалларга да мөмкинлек бирә. Шуңа да, халык тормышын өйрәнгәндә бу аспектларга аерым игътибар бирү кирәк.

Фоторәсемнәрне автор тәкъдим итте

---

[13] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 190.
[14] Уразманова Р. К. Обряды и праздники татар Поволжья и Приуралья (Годовой цикл XIX – нач. XX вв.). – Казань: ПИК «Дом печати», 2001. – С. 58.
[15] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 66.
[16] Шунда ук. – Б. 144.

# Арчаның үз бизәкләре бар

2010 елда Арча районы Мәдәният йорты каршында «Арча бизәкләре» халык уен кораллары ансамбле оештырыла. Аны Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, югары һөнәри белемле музыка укытучысы, шулай ук халык уен кораллары оркестры дирижеры Филарит Мөнир улы Гасимов җитәкли. Әлеге ансамбль 1970 елдан бирле Арча районы Мәдәният йортында эшләп килүче гармунчылар ансамбленнән үзгәртеп корыла.

Коллектив 8 кешене – Арча педагогика көллияте, Арча балалар сәнгать мәктәбе укытучыларын, Арча районы Мәдәният йорты хезмәткәрләрен берләштерә. Ансамбль солистлары баянда, гармунда, тальянда, курайда, кубызда, скрипкада, бас-гитарада һәм шау-шулы уен коралларында уйныйлар. Репертуарларында милли композицияләр, татар халык көйләренә вариацияләр (попурри), татар халык җырлары, татар композиторлары әсәрләре урын алган.

2018 елда «Арча бизәкләре» халык уен кораллары ансамбленә «Халык коллективы» исеме бирелә. Бүгенге көндә ансамбль Арча районының йөзек кашы булып тора һәм район данын республиканың, аннан читтәге күп кенә иҗат мәйданчыкларында таныта.

«Арча бизәкләре» ансамбле репертуарын елдан-ел яңартып тора, районда, республикада үткәрелгән төрле конкурс-фестивальләрдә катнашып, җиңүләр яулый. Татар көен, татар моңын саклауга үзләреннән гаять зур өлеш кертә.

Коллектив халкыбызның көй-моңнарын, халык уен коралларында уйнау серләрен яшь буынга да тапшырырга тырыша.

**Ләйлә ХӘКИМОВА,**
**Арча районы Мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе**

**Фоторәсемнәр Арча районы Мәдәният йорты архивыннан**







**Егерме биш томнан торган «Татар халык иҗаты» басмасының тугызынчы томына татар халкының хәзерге заманга килеп җиткән дастаннары, кайчандыр көйләп һәм сөйләп башкарылган эпик ядкарьләре тупланган. Шуларның берсен сезгә дә тәкъдим итәбез.**




# Мактымсылу

Борын-борын заманда бер бай булган. Аның бер улы белән бер кызы булган. Чарлашу[1], сугышуны белгәннәре юк, тату яшиләр. Улы – ир (егет була), кызы буй җитә. Аталары, картлыгы җитеп үләр алдыннан, улы белән кызын чакырып, болай ди:

– Минем күз алдымда ничек тордыгыз, минем күзем югалгач та, шулай ук торыгыз, калган малны тиң бүлегез, – ди дә үлеп китә.

Әниләреннән кечеләй үк калганнар икән, аталары үлгәннән соң, тома ятим булып калганнар.

Агасы ауга йөри. Мактымсылу көне буе ялгыз тора. Кичләрен дә агасы, кайтып, үз өенә кереп китә, бу үз өендә була. Иртә белән генә Мактымны күреп чыга да тагы китә.

Беркөнне Мактым төш күрә. Иртән аны агасы янына кереп сөйли:

– Бүген ятып, әй, төш күрдем, агай,
Төшемдә яман күрдем мин, агай:
Уң якта чәчем җәюле, агай,
Сул якта чәчем үрүле, агай.

Агасы аңа каршы:
– Кызның бер төше төшме иде, Мактым,
Какырып бер төкерү җитмәсме, Мактым? – дигән дә, ук-ягысын[2] алып, кош җитмәс кола атын менеп, ауга китеп барган.

Мактым, елап-сыктап, көнне тагын ялгыз үткәргән, төнлә ятып, тагы шул ук төшне күргән. Иртән агасы янына кереп, тагы:
– Бүген ятып бер төш күрдем, агай,
Төшемдә яман күрдем мин, агай:
Уң якта чәчем җәюле, агай,
Сул якта чәчем үрүле, агай, – дип сөйләгән.

[1] Чарлашу – кычкырышу.
[2] Ук-ягы – ук-җәя.

Агасы:

– Кызның бер төше төшме иде, Мактым,
Какырып бер төкеру җитмәсме, Мактым? –

дип, үз юлына киткән.

Мактым, тагы елай-сыктай, өендә калган.

Көн үткән, төн килгән, төнлә шул ук төшне күрә. «Бу яхшылыкка түгел, бер төш яхшылыкка гына өч тапкыр керми», – дип, тагын абыйсы янына кереп сөйләгән. Абыйсы, тагын колагына элмичә, шул «кызның бер төше төшме иде, Мактым» сүзен кабатлап, җил җитмәс җирәнен менеп, авына чыгып китә. Айлар буе киң юлларны тар итеп йөрсә дә, юлы уңмаган, буш кул белән борылып кайткан.

Өенә кайтса, капкалар, ишек-тәрәзәләр каерылган, бар йорт-җир ватылган. Өенә керсә, Мактым да юк икән. Сеңеп калгандай утырган-утырган да бу, берәүне дә күрмичә, сөйләшмичә, җил җитмәс җирән атын үләннең куесына, суның сыегына җибәреп, кош җитмәс коласын менеп, Мактымны эзләп чыгып киткән.

Моннан торып, күз җитмәс, колак ишетмәс җирдә Тимер ханның Тайчы атлы улы җир тетрәтеп, күк күкрәтеп көн күреп яткан икән. Алдыннан килсәң – Көнсылу, янышнан килсәң Айсылу булган Мактымсылу барлыгын ишетеп, Тайчы, иле-явы белән килеп, Мактымның илен-халкын үтереп, үзен урлап киткән. Ай үтәрне көн үтеп, Тайчының җиренә җиткәннәр. Сыгыт-үгет[3] эчендә өч-дүрт ел гомер узып киткән. Мактымның ике баласы булган. Ничек кайтырга әмәлләсә дә, Тайчы һаман сизенеп тотып калып торган.

Беркөнне шулай иртән торсалар, кара болыт кебек, тузан-туфрак куптарып, яу килә, ди. Тайчы, яу шайманын[4] киеп, атын менеп, халкын җыеп, яуга каршы киткән. Яуның кызган төшендә елкысын менеп, Мактым да яу башына чыккан. Яуга караса, агасы, илен алып, яуга килгән, ди. Ул сеңлесен дүрт ел буена эзләп, Мактымны Тайчы урлаганын белеп, яу белән килгән икән.

Мактым, агасы Тимер ханны җиңсә дә, Тайчыны җиңә алмаячагын белеп, аңа болай ди:

– Җил җитмәс җирәнең менгәнсең, агай,
Җилкенеп яуга кергәнсең, агай.
Бер минем өчен килгәнсең, агай,
Үлсәң дә шәһит булмассың, агай,
Атың башын тарт, агай! – дигән.

Агасы бер як яныннан яраланган икән, сеңлесен танып, аның сүзен тыңлап, яудан чыгып киткән. Агач төбе салкынында ятып, әзрәк ял иткән дә, яуга карап, тагы сикереп торып киткән. Кола атын менеп, яуга кергән. Агасының яуга кергәнен күреп, Мактымсылу тагы:

– Кош җитмәс колатың менгәнсең, агай,
Кулаулап[5] яуга кергәнсең, агай.
Бер минем өчен килгәнсең, агай,
Үлсәң дә шәһит булмассың, агай,
Атыңның башын тарт, агай! – дигән.

Яу шайманына кан тулгач, ил халкы сирәгәйгәч, агасы, яудан чыгып, халкын ияртеп, өенә кайтып киткән.

Тайчы белән Тимер хан да яудан өйгә кайталар. Мактымсылу боларны сугышып җиңеп булмасны белә дә берәр хәйлә эзли башлый.

Беркөнне ул шемәкчен[6] карчыгы барлыгы турында ишетеп, аңа үзенең моннан качарга уйлаганын әйтә. Шемәкчен аңа шундый киңәш бирә:

– Сезнең әле туегыз булмаган, туй ясарга күндер. Туйга авы-сәре[7] итеп аракы кайнат, – дигән.

Мактымсылу көн дә, төн дә ирен туй ясарга кыстый башлый:

– Дүрт-биш ел гомер итеп, ике бала үстереп, кеше шикелле бер туй уздырмадык, син дә кеше булгансың, – ди Тайчыга.

Тайчы әүвәле һич риза булмый, соңыннан туй ясамакчы була.

---

[3] Сыгыт-үгет – елаш-үгет.
[4] Яу шайманы – яу кием-салымы һәм кораллары.
[5] Кулаулап – куалап.
[6] Шемәкчен – сихерче.
[7] Авы-сәре – агу-зәһәре.

Мактым үзе дигәнчә бик күп азык әзерли. Тайчы ил халкын җыя да тирә-якны күкрәткән туй башлый.

Мактымсылу Тайчыларга агу-зәһәр эчереп еккан да ике баласын йоклатып чыгарга дип киткән. Ишеккә килсә, Тимер хан ишеккә аркылы яткан, Мактымсылу аның аркылы атлап чыккан да атларның өзәңге бауларын кисеп салган, үзенең өеннән килгән ак атын менеп качып киткән.

Ак атның кузгалып китүе була, җир җимереп, күк күкрәтеп, Тайчының аты кешнәп җибәрә, ияләрен уята. Уянып карасалар, Мактымның эзе суынып ята. Куып китәргә чыксалар, өзәңге баулары өзелгән. Менәргә аяк бассалар, тупырдашып егылып төшәләр. Өзәңгеләрен яңартканчы, күп заманнар узып, Мактым күп җирләрне үтеп китә.

Аттан төшеп җирне тыңласа, тегеләр җитеп киләләр, ди. Артына әйләнеп, бер күзгә ташлаган икән, күз җитмәс, кош үтмәс күл булып киткән. Бу күлнең бер ягында саклап утырган. Ул ара да булмый, әлеге көч-фәрман чабып килгән Тайчы кешеләре белән шул күлгә килеп төртелә. Ары чабып, бире чабып карыйлар, – күлне үтеп чыга алмыйлар. Шуннан торып, Тайчы:

– Ник качтың? Кайт кире! – дип ялына башлый.

– Ике баламны алып кил! Алар кайгысыннан кайтырмын! – ди.

Ләкин Тайчы ике баласын алып килеп, дәрьяга ташлый.

– Шул ике балам минем юлымны тотып тора иде, инде синдә һич кызганырдай нәрсәм юк! – ди Мактымсылу. Ак аты өстендә бер мәртәбә очкын кебек ялтырап ала да Мактым күздән югала.

Тайчыныкылар күз җитмәс күлне әйләнеп килеп җиткәнче, Мактымсылу өйләрен, тимердән койдырып, койма белән әйләндереп алган.

Берзаманны җир җимертеп, кара болыт булып, Тайчыныкылар килеп җиткәннәр. Алай да итәләр, болай да итәләр, койманы җимерә алмыйлар. Аларны Мактымсылуның агасы иле-халкы белән эчтән торып ук-ягы белән кыра башлаган. Бер ягын кырып торса, икенче ягыннан үсеп торалар икән. Шуннан Мактым агасына әйткән:

– Аларны болай җиңеп булмаячак. Мин алар белән ашык[8] уйнап карыйм, – дигән.

Агасы халкын атышудан туктаткан. Халкы ни була дип аңышмый торганда, өй түбәсенә, ай-көн кебек балкып, Мактымсылу менеп баскан:

– Халыкны кырасы түгел. Өч көн, өч төн ашык уйныйк. Тайчы җиңсә, мин кайтырмын. Мин җиңсәм, оятыгызны яшереп, сез кайтып китәрсез, – дигән.

Ул арада Мактымсылу торган җиргә әлеге шемәкчен карчык килеп чыккан да ашык уйный башлаган. Ул уйныйлар – ул юк, бу уйныйлар – бу юк, өч көн, өч төн шулай уйнап, өчесендә дә Мактымсылу җиңеп чыга. Шемәкчен карчык ашыкларны ишегалды ягына чәчеп җибәрә дә Мактымсылу урынына менеп баса:

– Өч көн, өч төн янәшә утырып ашык уйнадык – мине танымадың, җиңә дә алмадың. Инде пистереп[9] йөрмәгез, мин сезне күрмим, сез мине күрмәгез, – дип әйтә дә төшеп китә.

Тайчыныкылар сугышта Тимер ханны аксатып (коймага менәргә маташканда, аягын сындырган ул), өметләрен өзеп, оятларын яшереп кайтып киткәннәр.

Мактымсылу әле дә булса ил халкының, агасының куанычы, юанычы булып тора, ди.

**Татар халык иҗаты: 25 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. – 9 т.: Дастаннар / (төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. И.Г. Закирова). – 2023. – 483 б.**

[8] Ашык – кузна (уен).
[9] Пистереп – яманлашып, эч пошырып.

# Туган тел көне иртәсендә...

Татарстан Республикасының «Иң яхшы мәктәп» исеменә лаек булган, «Казан мәгарифе командасы-2024» шәһәр бәйгесендә җиңү яулаган, күп кенә грантлар иясе, Каюм Насыйри премиясе лауреаты Казандагы Абдулла Алиш исемендәге 20нче гимназиядә бүгенге көндә 757 укучы белем ала.



Биредә уку елы дәвамында төрле чаралар уздырыла. Күптән түгел гимназиядә, туган тел айлыгы кысаларында, «Халыклар дуслыгы» фестивале үтте: һәрбер кабинет бер илгә багышлап бизәлде, аларның мәдәнияте, гореф-гадәтләре, тарихы, аш-сулары тәкъдим ителде, җыр-биюләре күрсәтелде.

21 февраль – Туган тел көне иртәсе «Туган тел» җыры белән башланып китте. Бу көнне төрле телләрдә шигырь уку бәйгеләре узды, газеталар чыгарылды, кызыклы, танылган шәхесләр белән очрашулар үткәрелде.



# Тукай безнең күңелләрдә...



**Рәйханә Степанова,**
*Кукмара, 7нче «Кыңгырау» балалар бакчасы тәрбиячесе*

**Шүрәле:**

Син кем? Нигә минем урманымда рөхсәтсез йөрисең?

**Су анасы:**

Су анасы мин, Су анасы, әллә танымыйсыңмы?

**Шүрәле:**

Су анасы булгач, үзеңнең күлеңә бар. Минем урманымда нигә йөрисең?

**Су анасы:**

Бик барыр идем дә, минем бик зур үтенечем бар сиңа, җәй көне, ялгышып, алтын тарагымны басмада калдырган идем, бер авыл малае тарагымны урлап качты. Менә мин шул малайны эзлим. Булыш әле миңа, урман хуҗасы.

**Шүрәле:**

Беләм мин ул гаиләне. Ул малайның абыйсы – Былтыр, бармакларымны кыстырды. Әле дә авыртып тора.



**Су анасы:**

Белгәч әйт тизрәк, кайда ул авыл? Кайда ул малай?

**Шүрәле:**

Авылмы?

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр.

Жырлаганда көй өчен тавыклары жырлай диләр.

**Су анасы:**

Соң әйдә, киттек тизрәк шул Кырлайга!

**Шүрәле:**

Йә, хәзер барырбыз. Ашыкма. Әйдә, мин сиңа башта урманымны күрсәтәм.

*(Сәхнәгә кәҗә белән сарык керәләр.)*

**Су анасы:**

Болар кемнәр тагын? Болар да урманда яшиләрме?

**Кәҗә:**

Исәнмесез, урман иярләре!

**Сарык:**

Урманыгызда төн кунарга рөхсәтме?

**Шүрәле:**

Кемнәр сез? Минем урманымда мондый җәнлекләр юк.

**Кәҗә:**

Без Сарык дус белән бер авылда бер ярлы гаиләдә яшәдек. Ашатырга ризык беткәч, чыгарып җибәрделәр.

**Сарык:**

Нишли инде мескен Кәҗә белән Сарык?
Икебезгә зур гына бер капчык тегеп,
Киттек менә кырга таба сәфәр чыгып.

**Шүрәле:**

Ә урман бит минеке!

**Су анасы:**

Калсыннар инде, бигрәк матур сөйлиләр бит.

**Шүрәле:**

Ярар, калыгыз, әнә теге аланлыкка барыгыз.

*(Кәҗә белән Сарык китәләр. Сәхнәгә сикерә-сикерә Гали керә.)*

**Су анасы:**

Бу бит минем тарагымны урлаган малай. Малай, китер минем алтын тарагымны!

**Гали:**

Бирермен, бирермен.

Мин сезгә табышмаклар әйтәм, тыңлагыз. Җавап бирә алсагыз, таракны бирәм.

Боз һәм кар эреде, сулар йөгерде,
Елап елгалар, яшьләр түгелде.
Көннәр озая, төннәр кыскара.
Бу кайсы вакыт? – Йә, әйтеп кара!

**Су анасы:**

Яз көне бит бу.

**Гали:**

Бик дөрес, молодец, Су анасы! Икенчесен тыңлагыз.

Ашлыклар үсте, башаклар пеште;
Кояш пешерә, тиргә төшерә.
Халык ашыга, китә басуга,
Урагын ура, бу кайчан була?

**Шүрәле:**

Җәй турында түгелме бу?

**Гали:**

Әйе, Шүрәле, дөрес. Тыңлагыз өченчесен.
Кырлар буш кала, яңгырлар ява;
Җирләр дымлана, бу кайчак була?

**Шүрәле:**

Яңгырлар күп яугач, көз көне түгелме бу?

**Су анасы:**

Барлык табышмакларга да җаваплар таптык, бир инде алтын тарагымны.

**Гали:**

Бирәм, Су анасы, бирәм тарагыңны. Бәйрәм бит бүген!

**Сарык, Кәҗә, Су анасы, Шүрәле бергәләп әйтәләр:**

Бар күңеллелек дөньяда, бар бер ямь бүген,
Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

**Автор фоторәсемнәре**

# Мәче белән шагыйрь

*Наилә Яхина көе, Нәҗибә Сафина сүзләре*




*Мәче малаен кочаклап,*
*Мин әле җыр язамын.*
*Мәче шуны укый-укый*
*Әйтеп тора азанын.*

***Кушымта:***

*Ышанмыйча хәлем юк, –*
*Соң, тарихта дәлил юк.*
*Мәче мырлый, шагыйрь җырлый, –*
*Шунсыз дөнья яме юк.*

*«Син җырыңны яз, – ди ул, –*
*Табигатьтә яз, – ди, ул –*
*Мин бит Тукай моңнарыннан*
*Өзелеп төшкән саз», – ди ул.*

***Кушымта.***

# Ризаэддин Фәхреддиннең «Әхлак гыйлеме» китабыннан...

## Ашау әдәпләре

Ашарга утырган вакытыгызда иң элек кулларыгызны юыгыз вә яхшы сөртегез!

Үзегездән олы кешеләр булганда, алардан элек утырмагыз!

Аш янында берни белән дә уйнамагыз, бәлки әдәпле генә булыгыз, тәмам туймастан элек туктагыз!

Тастымалны тезләрегезгә куегыз (кайберәүләр күкрәккә куюны дөрес күрәләр). Аштан бик ерак яки бик якын булмагыз, күршеләрегезгә тарлык итмәгез, бер нәрсәгә дә таянмагыз, бәлки туры утырыгыз. Ашаган вакытыгызда бераз бөгелегез!

Ашый башлаганда «бисмилла» укып, уң кулыгыз белән авыз итегез, ашап бетергәч, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтегез!



**Мулла өендә чәй эчү. Татарлар-мишәрләр. Уфа губернасы, Уфа өязе. М.А. Круковский фотоколлекциясеннән, 1911 ел. РЭм 2577-1**

Зур-зур алмагыз, ашыкмагыз, яхшы чәйнәгез, кул вә киемнәрегезне буямагыз, табактан үзегез өчен бер нәрсә дә сайламагыз, башкаларның ашавына карап тормагыз, комсыз булмагыз, күп ашарга гадәтләнмәгез, аштан күңелегез кайтканчы туктагыз, бу нәрсәләрнең сәламәтлек өчен файдасы күп икәнен үзегез дә белерсез.

Фикерегезне гел ашау өчен сарыф итмәгез, бәлки максатыгыз, тереклек итәр өчен ашау булып, ашау өчен тереклек итү булмасын!

Кайбер хайваннарның итләре адәм углының күңелен бозганы, дошманлык хисләренә тәэсир итүләре өчен, мөмкин кадәр булган ризыкларны сайлап алыгыз!

Ит ашамаган кавемнәр, башкаларга караганда сәламәт, куәтле, шат вә тырыш булганнары өчен вә яшь вакытта һәрнәрсәгә гадәтләнү мөмкин булып, яшьлектә гадәтләнмәгән нәрсәләрне файдаланырга нәфес һичбер заман мәҗбүр булмаган өчен, ит ашамаска яшьлегегездә гадәтләнегез. Суеласы җан иясенең куркып күзеннән яше аккан хәлдә, аны чалып һәм кайнар казанга салып, итен пешереп ашамый тору да – адәм углы өчен олуг гөнаһ булмаса кирәк.

**Ашый башлаганда «бисмилла» укып, уң кулыгыз белән авыз итегез, ашап бетергәч, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтегез!**

Сөйләшеп ашалган аш җиңел сеңсен өчен, кычкырышу, сүз үлчәштерүдән башка, ягъни әдәп белән генә сөйләшегез!

Кулыгызны табакка батырмагыз һәм ашка буямагыз!

Тәмам пешмәгән җимешләрне ашамагыз, эссе вакытларда майлы ашаудан сакланыгыз!

Вакытлы ашарга өйрәнегез, вакыты җитеп тә ашарга теләгегез булмаса – көчләп ашамагыз, ашаган вакытыгызда киемнәрегез тар вә кысан булмасын, шулай ук олы кайгылы вә шат вакытыгызда бераз булса да сабыр итегез!

Авызыгызга алган нәрсәләрне тәмам чәйнәгез, ашыкмагыз, артык озакка сузмагыз, бәлки егерме вә утыз минут арасында тәмам итегез, ашавыгыздан ике сәгать үтми торып йокламагыз вә бик авыр эшләр эшләмәгез!

Никадәр олы ялгышы булса да, аш янында һичкемне шелтәләмәгез вә һичкемнең гайбәтен сөйләмәгез!

Аштан соң кул вә авызларыгызны сабын белән бик яхшы юыгыз, теш арасында бер нәрсә калдырмагыз, мөмкин булганда йокламыйча бераз ятып торыгыз!

## Эчү әдәпләре

Ашаган вакытыгызда эчәсе булсагыз, авызыгызда булганны йотып бетергәннән соң эчегез, эчкәннән соң киемегез яки кулыгыз белән түгел, бәлки авызыгызны тастымал белән сөртегез!

Сәламәтлек өчен (күп булмау шарты белән) саф су мәртәбәсендә һичнәрсә булмаганы өчен саф су эчәргә гадәтләнегез! Ләкин күл вә ислән-гән яки бозлы вә карлы сулар эчүдән сакланыгыз, ашагач ике сәгать үтми торып һәм йокыдан торуыгыз белән вә тирләгәннән соң, салкын су кулланмагыз!

Сөт, каһвә, чәй, лимон сулары – эчәргә яраклы нәрсәләрдер.

Әгәр дә яхшы булса – сөт олылар вә кечеләр өчен җиңел эшкәртелә торган эчемлектер.

Каһвә – әгәр дә сөт белән эчелсә, ашказанына файда вә азык эшкәртелүгә куәт бирер,

ләкин эссе мәмләкәтләргә яраклы бер эчемлектер.

Чәй – күп булмау шарты белән, салкын мәмләкәтләрдә файдалы эчемлектер, ашказанына куәт бирер. Хәсрәт белән гәүдәләре зәгыйфьләнгән кешеләргә ярдәм бирер.

Лимон сулары – эссе көннәрдә файдалы эчемлектер.

Ишетү, иснәү, күрү куәтләрен зәгыйфьләндергәне вә сулышны тарайтканы, ашыйсы килүне бетергәне өчен һич тәмәке тартмагыз!

барыгыз, йорт иясе белән шатлык белән күрешегез!

Мөмкин булганда үзегезгә яраклы кешеләр яннарына утырыгыз. Мәҗлес һәм ашау әдәпләрен камилләштерегез, һәрникадәр сөймәгән ризыгыгыз килсә дә, сөймәгәнегезне белдермәгез, ашларның гүзәл булмаганлыгыннан бәхәсләшмәгез, ашыйсыгыз килгәнне ашагыз, ашыйсыгыз килмәгәннәрен әдәп белән кире кайтарыгыз, бүлеп алмагыз!

Аш тәмам булып, куллар юылганнан соң

**Фикерегезне гел ашау өчен сарыф итмәгез, бәлки максатыгыз, тереклек итәр өчен ашау булып, ашау өчен тереклек итү булмасын!**

Малларны харап иткәне, үлемгә сәбәп булачак хәстәлекләрне китергәне өчен, исерткечләрнең һәртөрлесеннән бик сакланыгыз вә боларны файдаланган кешеләр белән хәтта дус вә белеш булмагыз!

## Кунак итү әдәпләре

Кунак чакырасы булсагыз, гореф вә гадәт буенча беркадәр вакытлар иртәрәк хәбәр итегез!

Кунакларны ачык йөз вә хөрмәт белән каршы алыгыз вә һәркемне тиешле урынына утыртыгыз!

Никадәр ләззәтле булса да, ашларыгызны мактамагыз, кунакларны ашар өчен кыстамагыз (бер яки ике мәртәбә әдәп белән генә әйтелсә, бәлки зарар итмәс), кунак итүченең вазифасы исә, кунаклар хозурына аш китерү булып, ашау вә ашамау – кунаклар ихтыярындадыр.

Кунакларның һәрберсе белән аз булса да яннарында беркадәр утырып сөйләшегез, киткән вакытларында шатлык күрсәтеп, исәнләшеп вә рәхмәт әйтеп калыгыз!

Кунакка чакырылган вакытыгызда, билгеләнгән вакыттан бераз минутлар элегрәк

рәхмәт укып, исәнләшеп кайтып китегез!

Мәҗлескә баруга берәр комачаулык булганда, бара алмаганыгызны белдереп, хәбәр җибәрегез!

Бер кешегә барганда икенче берәүнең мәҗлесеннән вә ашларының ләззәтле булмавыннан вә яки башка гаепләреннән сүз сөйләмәгез!

Үзегез чакырылмаган кешеләрнең мәҗлесләренә бармагыз!

Аш вә туй мәҗлесләрендә башкалардан көнләшеп, хәлегездән артык мал исраф итмәгез!

Вакыт алтын булганы өчен, бер сәгатьтән артык вакыт исрафителү тиеш булачак мәҗлесләргә бармагыз вә башкаларның гомерләрен исраф итәчәк мәҗлесләрне дә оештырмагыз!

**(«Татархана» проектының презентация материаллары җыентыгы ТАТАРХАНӘ / ТАТАРХАНЕ / TATARHANE Казан 2022)**

**Фоторәсем «Традиционная культура татар XIX-XX веков» (С-Петербург: АО «Славия», 2012) каталогыннан алынды**

# Бәрәңге шаңгәсе

«Татарханә» проектының «Татар табыны» рубрикасыннан. Мастер-классны «Тәмле булсын» рестораннар челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, танылган аш-су остасы **Резидә Кыям кызы ХӨСӘЕНОВА** алып бара



## КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР:

**Ачы камыр өчен:**
250 грамм сөт,
0,5 чәй кашыгы тоз,
100 грамм сыек май,
1 данә йомырка,
1 десерт калагы коры чүпрә,
кирәгенчә он.

**Эчлек өчен:**
800-900 грамм чистартылган бәрәңге,
1 данә йомырка,
тәменчә тоз,
200 грамм кайнар сөт,
130 грамм эретелгән атланмай.



**1** *Кирәкле булган ингредиентларны кушып, камыр басабыз.*



**2** *Камыр кабарган арада эчлек әзерлибез. Аның өчен әрчеп бәрәңге пешерәбез. Пешеп чыккач, аңа кайнар сөт, йомырка, эретелгән атланмай, тәменчә тоз кушып, бәрәңге боламыгы ясыйбыз.*



**3** *Әзер камырны 100 граммлы вак кисәкләргә бүләләп, түгәрәк җәймәләр җәябез.*



**4** *Әзер җәймәләргә бәрәңге боламыгы салабыз да өстенә йомырка сарысы сөртәбез.*



**5** *Әзер шаңгаләрне табага тезеп, 40 минутка 180 градуска кадәр җылытылган духовкага тыгабыз.*



**6** *Пешкән шаңгаләрне алып, эретелгән атланмай белән майлап, чәй табынына чыгарабыз.*
*Ашларыгыз тәмле булсын!*

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Бергәләп бизибез!



# Истәлекле даталар
2025

## АПРЕЛЬ

**9 апрель**

Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Наилә Әмин кызы Галәвиевага 70 яшь (1955)

**14 апрель**

Язучы, фольклорчы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Гомәр Толымбайның (Габделхак Җәләлетдин улы Шаһиәхмәтов) тууына 125 ел (1900-1938)

**15 апрель**

Фольклорчы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илбарис Нурислам улы Надировның тууына 100 ел (1925-2009)

**26 апрель**

Беренче татар профессиональ музыка белгече, педагог Хәлимә Ибраһим кызы Булатова-Терегулованың тууына 120 ел (1905-2000)

**30 апрель**

Актриса, ТАССРның атказанган артисты Нәфыйга Мөхәммәтгали кызы Арапованың тууына 125 ел (1900-1943)

## МАЙ

**6 май**

Сынчы, рәссам, Татарстан Республикасының атказанган архитекторы, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты Алмас Әхтәм улы Идрисовка 75 яшь (1950)

**13 май**

Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премия лауреаты Земфира Нәкый кызы Бикташевага 70 яшь (1955)

**22 май**

График, рәссам, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Илдар Каюм улы Әхмәдиевнең тууына 90 ел (1935-2011)

**23 май**

Композитор, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның һәм ТРның халык артисты, РСФСРның М.И. Глинка исемендәге һәм Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Фасил Әхмәтгали улы Әхмәтовның тууына 90 ел (1935-1998)

**23 май**

Фольклорчы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Флора Ваһап кызы Әхмәтова-Урманченың тууына 90 ел (1935-2007)

**25 май**

ТАССРның атказанган артисты Кәримә Әхмәт кызы Нуруллинаның тууына 100 ел (1925-2013)

## ИЮНЬ

**1 июнь**

Рәссам, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Илдар Азат улы Байбековка 70 яшь (1955)

**6 июнь**

Актёр, педагог, режиссёр, Татарстан Республикасының халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты Илдар Зиннур улы Хәйруллинга 75 яшь (1950)

**9 июнь**

Актриса, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык артисты Луара Галимҗан кызы Шакирҗановага 75 яшь (1950)

**10 июнь**

ТАССРның атказанган артисты Әхмәт Галиәкбәровның (Әлмәт театры) тууына 110 ел (1915-1991)

**10 июнь**

Рәссам Зөфәр Фатыйх улы Фәттаховка 70 яшь (1955)

**19 июнь**

График, нәкышьче, проектчы-бизәүче, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Владимир Леонидович Халтуринның тууына 120 ел (1905-1979)

**19 июнь**

Актёр, Татарстан Республикасының халык артисты, М. Җәлил исемендәге Республика һәм Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Илдус Хәниф улы Әхмәтҗановка 75 яшь (1950)

**19 июнь**

Рәссам-график, карикатурист Фәрит Алексеевич Вахитовка 75 яшь (1950)

**23 июнь**

Актёр, режиссёр, тәрҗемәче, радиорежиссёр, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Госман Нигъмәтҗан улы Әхмәтҗановның тууына 100 ел (1925-2005)

**23 июнь**

Журналист, публицист, тәрҗемәче, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Әнәс Хәсән улы Хәсәновның тууына 90 ел (1935-2024)

**28 июнь**

Балет артисты һәм балетмейстер, ТАССРның халык артисты Фердинант Минһаҗ улы Гыймадиевка 80 яшь (1945)

**30 июнь**

Актриса, Татарстан Республикасының халык артисты Зөләйха Рәфыйк кызы Хәкимҗановага 75 яшь (1950)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**







**Кадерле укучыларыбыз!**
2025 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 294 сум 07 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 588 сум 14 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!